• МИНБӘР •

НӘФЕЛ НАМАЗЛАР – АЛЛАҺТАН БҮЛӘК

*Әввәбин, хаҗәт, истиска, тәүбә намазларының фазыйләтләре, уку тәртибе хакында.*

*4 бит*

• УРАЗА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ •

НӘРСӘ УЛ КӘФФАРӘТ?

*Уразаны кайсы очракларда каза итеп тотарга һәм кәффарәт үтәргә дә кирәк була?*

*7 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •

КЫЯМӘТ КӨНЕНДӘ БИРЕЛӘЧӘК СОРАУЛАР

*Кыямәт көнендә безне ниләр көтә? Адәм баласыннан ниләр соралыр?*

*11 бит*

• ИМАНЛЫ ГАИЛӘ •

НИЧЕК БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘ ТӨЗЕРГӘ?

*Яшь мөселманнарны борчыган сорауларга тәҗрибәле педагог, психолог җаваплары.*

*12 бит*

*№ 5 (274)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *Шәгъбан – Рамаан 1439*

*Май, 2018*

# دين ومعيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

## Казанда VI Республикакүләм ифтар узды



# Берләшкән Милләтләр Оешмасы Диния нәзарәтенә консультатив статус бирде

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенә БМОның Икътисад һәм социаль советы (ЭКОСОС) каршында консультатив статус бирелде. Әлеге карар 2018 елның 17 апрелендә ЭКОСОСның Координация һәм идарә буенча утырышында кабул ителде. Аның барышында БМОның ЭКОСОС каршында Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенә махсус консультатив статус бирү турында НПО буенча Комитет доклады хуплау тапты. Шулай итеп, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Россиядә шундый статус алган беренче һәм бердәнбер мөселман дини оешмасы булып тора. Әлеге статус бирелү, һичшиксез, Татарстан Республикасында конфессияләр, мәдәниятләр һәм милләтләр арасында тотрыклы мөнәсәбәтләр тәэмин итү һәм традицион ислам кыйммәтләрен ныгыту өлкәсендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте эшчәнлеген халыкара дәрәҗәдә тану булып тора.

БМО офисларында төрле чараларда катнашу мөмкинлеге бирә торган консультатив статусны алу өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте гаризаны 2016 елда бирде.

Консультатив статус БМО тарафыннан хөкүмәтнеке булмаган оешмаларга (НПО) Икътисад һәм социаль совет каршында БМОның Уставы һәм башка төп документлары нигезендә бирелә. Консультатив статусның өч төре бар: ростер (чикле), махсус, гомуми (югары). Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте махсус консультатив статуска ия булды, ул ЭКОСОС белән генә түгел, БМОның күп кенә башка оешмалары һәм структуралары белән хезмәттәшлек алып бару мөмкинлеген бирә. Моннан тыш, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хәзер халыкара конференцияләрдә катнашу, язмача һәм телдән гаризалар белән чыгыш ясау, параллель чаралар оештыру мөмкинлегенә ия. Шулай ук БМО ЭКОСОС каршындагы консультатив статус, үз тәҗрибәсенә турыдан-туры таянып, төрле сораулар буенча эксперт анализы үткәрү, халыкара килешүләр үтәлеше мониторингын алып барырга ярдәм итү, җәмәгатьчелекнең игътибарын билгеле бер сорауларга юнәлтү, БМОның максатларын алга сөрүдә мөһим роль уйнау мөмкинлеге бирә.

■ **dumrt.ru**

## «Дини сорау» интернет-линиясе эшли башлады



Рамазан аенда Татарстан Республикасы мөфтиенең «Дини сорау» консультатив интернет-линиясе үз эшен башлап җибәрде. Ул теләгән һәркемгә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинга турыдан-туры сорау бирү мөмкинлеген бирү өчен оештырылды. Шәригатькә кагылышлы сораулар белән электрон почта аша мөрәҗәгать итеп була. Аның адресы: **dini.sorau@tatar.ru.** Сорауларны шулай ук Диния Нәзарәтенең сайтында «Мөфтигә сорау» дип исемләнгән сәхифәсе аша да җибәреп була.

Моннан тыш, ислам тематикасына бәйле булган сорауларга җавапларны Диния Нәзарәтенең Ышаныч телефоны аша да алып була. (843)50-50-700 яки +7(939) 50-50-700 телефоннарына шалтыратып, ТР мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллиннан консультация яки киңәш сорарга мөмкин. Ышаныч телефоны дүшәмбедән җомгага кадәр сәгать 10.00-17.00 кадәр эшли.

## Татар теле укытучысына – хаҗга юллама

ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм «ДУМ РТ Хадж» Татарстандагы рәсми хаҗ-операторы урта гомум белем бирү мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында «Минем халкым, минем динем» дип исемләнгән бәйге игълан итә.

Конкурс яшь буынны укытуда һәм тәрбияләүдә, татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен саклап калу һәм өйрәнүдә укытучыларның казанышларын хуплап, аларны кызыксындыру өчен оештырыла.

Бәйгедә җиңүчеләрне олы бүләк – 2018 елда хаҗга юллама көтә. Бәйгенең мәҗбүри шартлары булып белгечләре буенча кимендә 10 ел хезмәт стажы һәм көндәлек тормышта ислам дине нигезләренә таянып яшәү рәвеше, шулай ук, мәхрәме булуы тора. Мәхрәм (хатын-кызларны озата баручы ир-ат заты) хаҗга үз хисабына барачак.

Ислам дине нигезләре буенча белемнәр конкурста тест формасында тикшереләчәк. Бәйгенең нәтиҗәләре буенча 30 җиңүче билгеләнәчәк.

Конкурста катнашырга теләүчеләр гаризаларын 2018 елның 20 маена кадәр түбәндәге электрон почтага җибәрә алалар: **konkursdumrt@gmail.com.**

Белешмәләр өчен телефон: +7927 432-74-50

Бәйге турында Нигезләмә һәм гариза үрнәген dumrt.ru сайтында карарга мөмкин.

## «Рамазан – изге гамәлләр ае»



Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте һәм «Зәкәт» хәйрия фонды ел саен уздырыла торган «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия акциясен кабат башлап җибәрде.

Мәгълүм ки, мөбарәк Рамазан шәриф көннәрендә бөтен кешеләр изгелек кылуга, күпләп савап вә әҗер алырга омтылалар. Изгелек кылырга теләгән һәркем «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия акциясендә катнаша ала. Акция кысаларында авыру баланың дәвалану курсларына акча җыю, ифтар ашлары уздыру һәм башка саваплы гамәлләр каралган.

«Зәкәт» хәйрия фондына акча күчерү өчен 7715 номерына смс юлларга, шулай ук сәдакаларны түбәндәге реквизитларга күчерергә дә мөмкин:

Наименование сбора «САДАКА» («ЗАКЯТ»)

БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ФОНД «ЗАКЯТ»

ИНН/КПП 1655068682/165501001

ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012

Р/с №40703810362190000764

(Советское отделение №6669/015 СБ РФ г. Казани)

ОСБ БАНК ТАТАРСТАН №8610 г. Казани

к/с: 30101810600000000603

БИК:049205603

Юридический адрес: 420111, г. Казань, ул. Лобачевского, д.6

Адрес: 420111 г. Казань, ул. Лобачевского, д.6

# Рамазан ае чаралары Коръән күргәзмәсеннән башланды



16 майда, изге Рамазан аеның беренче көнендә, Чаллы шәһәре музееның күргәзмәләр залында (музей тарихында икенче мәртәбә) Коръән күргәзмәсе ачылды. Ул үз эченә Казан Кирмәненең «Кол Шәриф» музее Коръән коллекциясенең уникаль өлешен, күренекле шәмаил һәм тугра остасы, Г. Тукай бүләге лауреаты Нәҗип ага Нәккашның мәшһүр әсәрләрен, «Сабыр» ательесы теккән мөселман киемнәре үрнәкләрен, шәһәр «Хәләл-Үзәге» тәкъдим иткән дини сувенирлар һәм китапларны алды. Шулай ук музей дирекциясе күргәзмә ачылу көненә шәһәр мәчетләре турында махсус стенд та әзерләде. Анда шәһәрнең 14 мәчете турында мәгълүмат урнаштырылган.

Күргәзмәне ачу тантанасында шәһәр имамнары, сәнгать әһелләре, фән эшлеклеләре, мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаштылар. Күргәзмәдәге Коръән коллекциясе белән Казан Кремле ислам мәдәнияте музееның өлкән фәнни хезмәткәре Миләүшә Илгиз кызы Даутова таныштырды. Ә Нәҗип ага Нәккаш үз әсәрләре эчтәлеге, аларның язылу тарихы турында сөйләде.

Шәһәр музее директоры Румил Рәуф улы Карамиев (күргәзмә аның башлангычы белән Чаллы мөхтәсибәте булышлыгында оештырылды), шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Мәрван улы Хәлимов күргәзмәдә катнашучыларны җылы сәламләделәр һәм ошбу мөһим вакыйга белән чын күңелдән котладылар. Төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли исә халыкка мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның сәламнәрен ирештерде.

Рамил Мәрван улы күргәзмә белән шәһәр укучыларының да танышачагын белдерде. Чөнки ул Рамазан ае дәвамында, ягъни 15 июньгә кадәр эшләячәк.

■ **islamtatar.ru**

# «Kazan Islamic Clothes 2018»





Казанда «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit» X Халыкара икътисади саммит кысаларында «Kazan Islamic Clothes 2018» дип исемләнгән IX Халыкара мөселман киемнәре фестивале узды. Аны оештыручылар булып: Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, Россия Мөслимәләр берлеге, Россия Мөселман дизайнерлары берлеге тора. Әлеге проектның концепциясе Татарстан Республикасы имиджын күтәрү, мәдәни потенциалын арттыру һәм аның халыкара иҗади элемтәләрен киңәйтү бурычларына җавап бирә.

Фестиваль дизайнерлар һәм бар дөньядан модельерлар хезмәттәшлеге өчен мөмкинлекләр белән халыкара мәдәниятләр диалогын үстерү, исламча, милли кием стилен пропагандалау, профессиональ дизайнерларның иҗади элемтәләрен үстерү, профессионаллар һәм яшь белгечләрнең мода индустриясе өлкәсендә тәҗрибәсе һәм идеяләр алмашу өчен гомуми мәдәни киңлек формалаштыру; халыкара дәрәҗәдә мода һәм җиңел сәнәгать өлкәсендә бизнес үсеше һәм сәүдә өчен мөмкинлекләр тудыру максатында үткәрелде.

Конкурста профессиональ дизайнерлар, кием дизайнерларын әзерләүче һөнәри уку йортларын тәмамлаучылар, шулай ук мөстәкыйль авторлар, яшь дизайнерлар һәм модельерлар катнашты. Алар Төркия, Англия, Марокко, Индонезия, Дагстан Республикасы, Кыргызстан Республикасы, Үзбәкстан Республикасы, Чечен Республикаларыннан килде.

■ **dumrt.ru**

# Иң оста мөәзиннәр билгеләнде



12 май көнне Мамадыш мәдрәсәсе тарафыннан оештырылган районкүләм азан әйтү бәйгесе булып узды. Әлеге чарада районыбызның төрле авылларыннан һәм шәһәр мәчетләреннән килгән 70 кә якын катнашучы көч сынашты. Бәйге өч яшь категориясе (кечкенәләр, урта яшьтәгеләр һәм олылар) кысаларында алып барылды. Жюри әгъзалары катнашучыларга көйләп әйтүләренә, тәҗвид белән укуларына һәм яттан дөрес итеп башкаруларына карап бәя бирделәр. Нәтиҗәдә әлеге номинацияләрдән чыгып тугыз урын билгеләнде.

Кечкенәләр арасында: беренче урын – Гарипов Габделгазиз (Мамадыш), икенче урын – Вәлиуллин Йосыф (Кече Сөн), өченче урын – Хәбибуллин Таһир (Мамадыш).

Урта яшьтәгеләр арасында: беренче урын – Назмиев Фирназ, икенче урын – Биккинин Ильмар (Яңа Комазан), өченче урын – Галиев Салават.

Олылар арасында: беренче урын – Шәйдуллин Рафис (Түбән Сөн), икенче урын – Кәримов Фаил (Мамадыш), өченче урын – Мөбәрәкшин Зөлфәт (Мамадыш).

Җиңүчеләрнең һәрберсенә кыйммәтле призлар һәм акчалата бүләкләр тапшырылды. Чара ахырында барлык килгән кунаклар һәм катнашучылар шулпа, пылау һәм башка сыйлар белән сыйландылар. Азактан әлеге чараны уздырырга булышкан иганәчеләргә хаслап дога кылынды, теләкләр әйтелде. Барчалары ошбу мисалдагы бәйгеләр районыбызда дингә мәхәббәтне арттырыр, дигән өметтә калдылар.

■ **Фирая Ганиуллина, Мамадыш**

# Нәфел намазлар – Аллаһтан бүләк

**Һәр мөселман Раббысына якынаерга, Ул боерганнарны гына үтәргә һәм гөнаһлардан ерак булырга тели. Башка гыйбадәтләр кебек үк, намаз нәфесне тәрбияли. Күбрәк савап алырга, ихласлыгын арттырырга омтылучылар өчен өстәмә (нәфел) намазлар – зур мөмкинлек. Шундый намазларның кайберләрен уку тәртибе белән танышып китик.**



## Әввәбин намазы ничек укыла?

Әввәбин намазы алты рәкәгатьтән тора, ахшам намазыннан соң укыла һәм мөстәхәб (ягъни аны уку саваплы) санала.

«Әввәбин» сүзе «әвввәб» сүзенең күплек саны булып тора. «Әвввәб» сүзе ниндидер гөнаһ кылганнан соң, шундук истигъфар кылып, Аллаһтан ярлыкау сораган кешене белдерә. Шул рәвешле, әввәбин намазын «күп тәүбә кылучының намазы» дип аңлатырга була.

Әбү Һөрайра (Аллаһ аннан разый булсын) тапшырган хәдисләрнең берсендә Пәйгамбәребезнең болай дип әйтүе тапшырыла: «Кичке (ахшам) намаздан соң бернинди начар әйбер әйтми алты рәкәгать намаз укыган кеше унике ел гыйбадәт кылуга тиң савап алыр» (Тирмизи, «Саләт», 431). Башка хәдистә: «Кичке намаздан соң алты рәкәгать нәфел намаз укучының гөнаһлары кичерелер, хәтта алар диңгездәге күбек кадәр күп булса да», – диелә (Хәйсәми, «Мәҗмәүз-зәваид», II/230). Шулай ук хәдисләр җыентыкларында Расүлуллаһның (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) ахшам намазыннан соң дүрт рәкәгать нәфел намазы укуы һәм сәхабәләренә дә шуны киңәш итүе риваять ителә (Тәбәранидән тапшырыла).

Хәнәфи мәзһәбе галимнәре фикеренчә, бу намаз ахшам намазыннан соң ук алты рәкәгать итеп укыла. Әмма галимнәр арасында бу намазны ничәшәр рәкәгать итеп уку хакында төрле фикерләр бар. Кайберләре намазны алты рәкәгать итеп укып, сәлам бирергә кирәк, ә кайберләре икешәр рәкәгатьтән соң сәлам биреп укырга кирәк, дип саный.

■ **Islam-Today**

## Хаҗәт намазы

Хаҗәт намазы – берәр нинди хаҗәттән котылу өчен яки теләгәннәреӊ чынга ашсын өчен Аллаһка мөрәҗәгать итү намазы.

Дүрт мәзһәб галимнәре дә бу намазга дәлил итеп түбәндәге хәдисне китерә: «Кешенең ниндидер хаҗәте туса, ул тиешенчә тәһарәт алсын, аннан соң ике рәкәгать намаз укысын һәм мондый дога кылсын:

لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ الْحَلِيمُ الْكَرِيمُ سُبْحَانَ اللَّهِ
رَبِّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ
أَسْأَلُكَ مُوجِبَاتِ رَحْمَتِكَ وَعَزَائِمَ مَغْفِرَتِكَ
وَالْغَنِيمَةَ مِنْ كُلِّ بِرٍّ وَالسَّلاَمَةَ مِنْ كُلِّ إِثْمٍ
لاَ تَدَعْ لِي ذَنْبًا إِلاَّ غَفَرْتَهُ وَلاَ هَمًّا إِلاَّ فَرَّجْتَهُ
وَلاَ حَاجَةً هِيَ لَكَ رِضًا إِلاَّ قَضَيْتَهَا يَا
أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ

**Мәгънәсе:** «Аллаһтан башка гыйбадәткә лаек зат юк. Ул – Бирүче, Юмарт. Аллаһ бар нәрсәдән пакь, бөек Гарешнең Раббысы. Барча мактаулар Аллаһка – галәмнәрнең Раббысына гына.

Раббым, рәхмәтеңне һәм мәгърифәтеңне кирәкле кылган һәр саваптан насыйп булуын һәм һәр гөнаһтан иминлек телимен. Кичерелмәгән гөнаһ, коткарылмаган кайгы, канәгатьләндерелмәгән ихтыяҗымны калдырма. Ризалыгыңа туры килгән ихтыяҗларымны кабул ит. Әй, мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе булган Аллаһым!» (Тирмизи, «Витр», 17; Ибне Мәҗәһ, «Икамә», 189).

Бу намазны көннең кайсы өлешендә дә укырга була (намаз укырга тыелган вакытлардан кала).

■ **Islam-Today**

## Истиска намазы

Истиска намазы – корылык сәбәпле игеннәргә һәм хайваннарга зарар килгәндә, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорап дога кылу өчен укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Бу намаз ачык җирдә укыла. Барлык мөселманнар бергә җыелып кырга чыгалар. Бала-чагаларын һәм йорт хайваннарын да үзләре белән алалар. Һәркем тәһарәтле килеш, түбәнчелекле кыяфәт белән җәяү бара. Кырга җиткәч һәрбер кеше кыйблага таба борылып баса. Имам җыелган кешеләргә бик күп вәгазьләр сөйли. Җыелган мөселманнарга кылган гөнаһлары өчен тәүбә һәм истигъфар кылырга һәм үзара дошман булганнарга бер-берсеннән гафу үтенергә куша. Халык тәүбә-истигъфар кыла, бер-берсен гафу итә. Аннан соң һәркем ялгызы гына икешәр рәкәгать намаз укый.

Истиска намазыннан соң түбәндәге дога укыла:

اَللّٰهُمَّ اَسْقِ عِبَادَكَ وَارْحَمْ بَهَائِمَكَ

اَللّٰهُمَّ أَمَرْتَنَا بِدُعَائِكَ وَوَعَدْتَنَا بِإِجَابَتِكَ
فَقَدْ دَعَوْنَاكَ كَمَا أَمَرْتَنَا فَاَجِبْنَا كَمَا
وَعَدْتَنَا

اَللّٰهُمَّ إِنْ لَمْ تَرْحَمْ لِأَنْفُسِنَا لِكَثْرَةِ ذُنُوبِنَا
فَارْحَمْ صِبْيَانَنَا وَبَهَائِمَكَ

Әллааһүммә әскы гыйбәәдәкә вәрхәм бәһәә'имәк. Әллааһүммә әмәртәнәә бидугәә'икә вә вәгадтәнәә би'иҗәәбәтикә фәкадъ дәгәүнәәкә кәмәә әмәртәнәә фә әҗибнәә кәмәә үәгәдтәнәә. Әллааһүммә ин ләм тәрхәм лиәнфусинәә ликәс̣рати з̣үнуубинәә фәрхәм сыбйәәнәнәә үә бәһәә'имәк

**Мәгънәсе:** «Йә Рабби, колларыңны эчерт, хайваннарыңа Үз рәхмәтеңне ирештер. Йә Рабби, Син безгә дога кылырга боердың һәм догаларны кабул кылырмын дип вәгъдә бирдең. Без Сиңа Үзең боерганча дога кылабыз, Син биргән вәгъдәң буенча безнең догабызны кабул итеп ал. Йә Рабби, әгәр гөнаһларыбызның күплеге сәбәпле безгә рәхмәтеңне ирештермәсәң, гөнаһсыз сабыйларыбызга һәм хайваннарга рәхмәтеңне бир».

Әгәр беренче көнне истиска намазын укып дога кылганнан соң яңгыр яумаса, янә ике көн шул рәвешле истиска намазы укыла. Әгәр кырда истиска намазы укыганда яңгыр ява башласа, башларны яңгырга чылатып, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылына.

■ **«Гыйбадәте исламия» китабыннан**

## Тәүбә намазы

Тәүбә намазы – гөнаһлар өчен үкенеп, тәүбә һәм истигъфар кылыр өчен укыла торган ике рәкәгать нәфел намазы. Тәүбә намазы тәмамланганнан соң түбәндәге истигъфар укыла:

أَسْتَغْفِرُ اللهَ أَسْتَغْفِرُ اللهَ أَسْتَغْفِرُ اللهَ تَعَالَى
مِنْ كُلِّ ذَنْبٍ أَذْنَبْتُهُ عَمْدًا أَوْ خَطَاءً سِرًّا
أَوْ عَلَانِيَةً وَاَتُوبُ إِلَيْهِ مِنَ الذَّنْبِ الَّذِى
أَعْلَمُ وَمِنَ الذَّنْبِ الَّذِى لَا أَعْلَمُ إِنَّكَ
أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

Әстәгъфируллааһ, әстәгъфируллааһ, әстәгъфируллааһ тәгәәлә мин күлли з̣әнбин әз̣нәбтүһү гәмдән әү хата'ән сирран әү гәләәнийәтән үә әтуубү иләйһи минәз̣-з̣әнбил-ләз̣ии әгләмү үә минәз̣-з̣әнбил-ләз̣ии ләә әгләмү иннәкә әнтә гәлләәмүл-гүйүүб

**Мәгънәсе:** «Мин Аллаһыдан һәрбер гөнаһымның ярлыкавын сорыйм, ялгышлык белән кылган гөнаһларым һәм хаталык белән кылган гөнаһларым өчен дә, яшерен кылган гөнаһларым һәм яшермичә кылган гөнаһларым өчен дә, шулай ук белеп кылган һәм белмичә кылган гөнаһларым өчен дә тәүбә итәм, бик үкенәм. Йә Аллаһ, Син яшеренне дә белүче».

■ **«Гыйбадәте исламия» китабыннан**

# «Сәдака бирегез, чөнки ул сезне җәһәннәм утыннан саклар»

Рамазан – изге гамәлләр ае. Һәр мөселман бу айда күбрәк сәдакалар биреп, зәкәтләрен түләргә, Раббысының рәхмәтенә ирешергә омтыла. Бу төр гыйбадәтләрнең әһәмияте турында «Зәкәт» хәйрия фонды җитәкчесе Ирек хәзрәт Җиһаншин белән сөйләштек.

***– Ирек хәзрәт, Ислам динендә сәдаканың әһәмияте турында әйтеп китсәгез иде.***

– Сәдака дигәндә – ул Коръәни Кәримдә бик күп урыннарда киләторган гыйбарә. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә бар мөэмин мөселманнарны сәдака бирергә өнди. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлләм: «Кем дә кем сәдака бирсә, Аллаһы Тәгалә ул кешене бик күп бәла-казалардан, кайгылардан, хәсрәтләрдән саклар», – дип әйтә. Башка бер хәдистә: «Сәдака бирегез, чөнки ул сезне җәһәннәм утыннан саклар», – диелә. Шулай ук Пәйгамбәребез сәдака бирүче турында сөйләгәндә ике бармагын күрсәтеп: «Ике бармак бер-берсенә ничек якын, ул кешеләр дә, җәннәткә лаек булган кешеләр, җәннәттә минем янымда шулай булырлар», – дип әйтә. Шулай итеп, Коръән аятьләреннән, Пәйгамбәребезнең бу хәдисләреннән сәдака бирүнең изгелек кылу, Аллаһы Тәгаләгә якынаю икәнен аңлыйбыз.

Сәдака бары тик акчалата гына бирелми. Мисал өчен, ир үзенең хатынына елмайса, хатын-кыз үзенең иренә елмайса, алар бер-берсенә сәдака биргән кебек савап алалар. Әгәр ир кеше үзенең гаиләсенә ризык алып кайтса, тәэмин итсә, үзенең гаиләсе алдында, балалары, хатыны алдында сәдака биргән кебек була. Әгәр дә бер кеше юлда барганда, башка кешеләргә йөрергә комачаулый торган бер әйберне күреп, аны кырыйга алып куйса – ул да бер сәдака. Һәм бу кешенең иманлы булуын күрсәтә торган гамәл.

Әлбәттә, бүгенге көндә сәдака бирү бик мөһим, чөнки ул социаль яктан безнең җәмгыятебезне үсешкә алып бара, фәкыйрь булган кешеләргә үсешкә этәргеч була. Кайбер ислам галимнәре әгәр дә сәдакалар бирелсә, зәкәтләр түләнсә, бу дөньяда бер фәкыйрь кеше дә калмаячак, ди. Без үзебез мөмкин булган кадәр фәкыйрьләргә, мескеннәргә ярдәм кулы сузарга тиеш. Кабатлыйм, ул бары тик акча белән түгел: бер эбигә дару алсак, ятим бер балага әйберләр алынса, кешегә ризык бирелсә, ул да бер сәдака була.

***– Сәдаканы кемнәргә бирергә ярый? Беренче чиратта кемнәргә бирергә кирәк?***

– Сәдаканы беренче чиратта мохтаҗ булган кешеләргә бирергә кирәк. Әлбәттә, башта моны мөмкин кадәр тикшерергә кирәк. Кызганыч, бүген ялганчылар да аз түгел, шуннан соң кешеләр хәйрия фондларына да башкача карыйлар, бу бер проблема. Сәдаканы диненә, тән төсенә, теленә карамыйча, мохтаҗ булган кешегә бирергә кирәк.

***– Рамазанда фитр сәдакасы, фидия сәдакалары бирелә. Аларның күләме нинди, кемнәргә бирелергә тиеш?***

– Фитра сәдакасы – һәрбер мөселман өчен, әгәр ул исән-имин Рамазан аена кергән икән, уразасын тоткан икән, вәҗиб булган гамәл. Ул Рамазан аеның махсус сәдакасы, бары тик шушы айда, Ураза гаетенә кадәр бирелергә тиеш. Бүгенге көндә голәмәләр шурасы карары белән аның күләме билгеләнгән. Иң кимендә 100 сум, байлар 600 сум бирәләр. Фитра сәдакасы арпа белән, йә йөзем бәясе белән билгеләнә, шуңа күрә шундый саннар чыга. Зәкәт түләүчеләр, димәк, 600 сум бирә. Фитра сәдакасын да, фидияне дә, беренче чиратта мөселманнарга бирергә тырышырга кирәк. Фитра ул кешене сөендерә торган сәдака, мохтаҗлар да бәйрәмне тоеп, гаетне сөенеп каршы алсыннар, дип бирелә ул.

Фидия сәдакасы – төрле сәбәпләр белән ураза тота алмаган мөселман бирергә тиешле сәдака. Ул тота алмаган һәр көн өчен бирелә. Аның күләме – кимендә 200 сум. Ул фәкыйрьләргә ризык бирүгә тотылырга тиеш. Мисал өчен, безнең «Зәкәт» фондына төрле регионнардан, хәтта чит илләрдән – Нигерия, Африканың башка илләреннән мөселманнар мөрәҗәгать итәләр. Без фидия сәдакаларын аларга да тапшырабыз.

***– Зәкәтне кемнәр түләргә тиеш? Нисабның нәрсә икәнен аңлатып китсәгез иде.***

– Нисаб – ул һәрбер мөселманның матди хәлен билгели торган бер чик. Алтын белән ул 83 грамм. Менә шушы 83 грамм алтын акчага күчереп караганда 210 мең сумга тигез була. Пәйгамбәребез: «Бер малдан, әгәр бер һиҗри ел узмаса, зәкәт бирелми», – дип әйтә. Моны ничек аңларга? Мисал өчен, кеше менә шушы нисабка ия булды, 83 грамм алтыны (210 мең сум акчасы) булды, шул көнне ул үзенә билгеләп куярга, истә тотарга тиеш. Бу көннән башлап, бер һиҗри ел узганнан соң, аның шушы нисабы сакланса яки артса, ул зәкәт бирергә тиеш. Акчадан 2,5% зәкәт бирелә, мисал өчен, берәүнең 40 сарыгы булса, 1 сарык бирелә. Зәкәт бирүче Аллаһ ризалыгын ала, Аллаһы Тәгалә аңа көтелмәгән җирләрдән тагы бәрәкәт бирә.

Үз акылында булган, ирекле, бурычлары булмаган һәм нисабы булган мөселманга зәкәт түләү фарыз. Зәкәт – динебезнең бер әркәне, шәһадәт китергәннән һәм намаздан соң зәкәт килә. Әгәр дә кемдер моны кабул итми, кире кага икән – көферргә төшә, Аллаһ сакласын, иманнан чыккан була. Әгәр берәү белеп тә, зәкәтне түләми икән, ул гөнаһлы була. Зәкәтнең дә җәмгыятьтә әһәмияте бик зур. Әлбәттә, бу Аллаһ ризалыгы өчен эшләнә торган гамәл.

***– Берәү йорт салырга, хаҗга барырга акча җыя, ди. Аның нисабы булса, ул шушы акчадан да зәкәт бирергә тиешме?***

– Әгәр дә бер мөселман фатир алырга, дәваланырга, машина алырга, хаҗга барырга һ.б. акча җыя икән, һәм бер ел дәвамында нисабы була икән, мондый акчалардан да зәкәт түләргә тиеш.

***– Зәкәт акчаларын кемгә бирергә һәм беренче чиратта кемгә бирергә кирәк? Кемнәргә бирергә ярамый?***

– Зәкәт акчаларын кемнәргә бирергә дигәндә, Аллаһы Тәгалә моны «Тәүбә» сүрәсенең 60 аятендә күрсәтә. Беренчедән, ул фәкыйрь мөселманнарга бирелә, икенчедән – мескеннәргә, ягъни ашарларына ризыклар, торыр урыннары да булмаган мөселманнарга, өченчесе – зәкәт җыючы махсус кешеләргә, безнең фондыбыз да турыдан шушының белән шөгыльләнә. Дүртенчесе – әле генә Ислам динен кабул иткән, әмма йөрәкләре әле динебезгә җылынып бетмәгән кешеләргә. Бишенчесе – бурычларын түләргә көче җитмәгән мөселманнарга. Алтынчысы – Аллаһы Тәгалә юлында йөрүчеләргә: мәдрәсә шәкертләре, остазлар, Коръәнхафизләр, дәгъват кылучылар. Алга таба – коллыктан котылырга теләгән кешеләргә. Әлхәмдүлилләһ, бу безнең җирлектә юк, әмма ишетеп беләбез, дөньяның төрле төбәкләрендә, мисал өчен, Мьянмада, мөселманнарга карата золым кылына, аларны коткарыр өчен хәтта сатып алалар. Бүгенге 21 гасырда да без шушындый әйберләр турында ишетә алабыз. Һәм соңгысы – ул юлда акчасыз калган мосафирларга.

Зәкәтне, беренче чиратта, мохтаҗ булсалар, үзебезнең бертуган ир кардәшебез, кыз кардәшләребезгә бирергә тиешбез. Аннан әти ягыннан апа-абый, әни ягыннан апа-абыйларга. Әгәр алар да бай булсалар, ул вакытта башка туганнарыбызга булышабыз. Әгәр туганнар арасында фәкыйрьләр юк икән, ул вакытта фәкыйрь булган күршеләребезгә бирергә тиешбез.

Ә кемнәргә бирергә ярамый? Зәкәтне үзеңнең әти-әниеңә, дәү әти-әниеңә, балаларга, хәләл җефетеңә (ирләргә дә, хатыннарга да), Пәйгамбәребезнең нәселеннән булган кешеләргә, мөселман булмаганнарга, бай булган кешеләргә, 7 яшьтән кече булган балаларга, психик авыруларга бирергә ярамый.

***– Рамазан аенда һәркем изге гамәлләрне күбрәк кылырга тырыша. Укучылар сезнең фондның нинди проектларына ярдәм итә ала?***

– Хәзерге вакытта без эшчәнлегебезне күбрәк авыру балалар юнәлешендә алып барырга тырышабыз. Телевидение, социаль челтәрләр аша соңгы мәгълүматларны алып торырга була. Моннан тыш, бу балаларның әти-әниләренә дә ярдәм итәбез. Яңа проектыбыз – махсус үзәк: авыру балаларга монда төрле дәресләр үткәрелә, ә шул ук вакытта аларның әниләре ялларын файда белән уздыра – алар тегәргә өйрәнә, кул эшләре белән шөгыльләнә, макияж ясау, бию буенча мастер-класслар узалар. Әниләр психологик яктан бик ял итә. Моннан тыш, без атнага 4 мәртәбә мохтаҗларны кайнар хәләл ризыклар белән ашатабыз, шул ук вакытта алар белән дәгъват эшен алып барабыз: сукбайларны өйләренә кайтырга өндибез, исерек хәлдә килүчеләрне ашатмыйбыз, аек килүләрен сорыйбыз, шуннан алар икенче, өченче килүләрендә аек була. Лобачевский 6 адресы буенча кием кабул итү һәм тарату пункты бар.

Форсаттан файдаланып, шуны хәбәр итәсем килә: хәзерге вакытта Казанда Зорге һәм Дубравная урамнары кисешендә яңа мәчет салына башлый. Ул бик матур мәчет булачак, Г. Утыз-Имәни исемен йөртәчәк, ин шә Аллаһ. Бар милләттәшләребез, дин кардәшләребезнең төзелешкә ярдәм кулы сузуларын өмет итеп калабыз, чөнки ул сәдака-җәрия. Пәйгамбәребез кеше үлеменнән соң аңа өч әйбер ярдәм итәчәк, ди: укыган Коръәне, ул кешенең балаларының догалары, һәм кое казыту, мәчет салдыру кебек изге гамәлләр. Мәчет салдыруда хәтта бер кирпеч өчен акча бирелгән булса да, бу сәдака-җәрия булып, Кыямәт көненә кадәр бара торган сәдака төре булачак, шул мәчеттә кылган намаз саваплары мәчет салуда катнашучыларга сәдака булыр, ин шә Аллаһ. Рамазан аенда мондый гамәлләрнең савабы тагы да арттырыла. Ярдәм итәргә теләүчеләр 3116 кыска номерына: **kazan [буш ара] сумма** – смс-хәбәрен җибәрә ала. Сәдака, зәкәт буенча сораулар белән «Зәкәт» хәйрия фондына (843) 225-33-22 номерына шалтыратырга мөмкин.

# Рамазан ахыры – җәһәннәм утыннан котылу көннәре

Бөтен галәмнәрнең Раббысы булган, безне төрле нигъмәтләр белән нигъмәтләндергән Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә иксез-чиксез рәхмәтләребез, мактауларыбыз, шөкраналарыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә тарафыннан галәмнәргә рәхмәт, мәрхәмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд хәзрәтләренә (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын), аның хөрмәтле әһленә, сәхабәләренә барчабызның сәламнәре, салаватлары һәм һәртөрле изге догалары булса иде. Ислам диненең хаклыгына ышанып, Ислам шәригате белән гамәл итүче мөхтәрәм мөселманнар! Аллаһы Тәгалә бөтен айларның солтаны булган мөбарәк Рамазан аенда тоткан уразаларыбызны, укыган тәравих намазларыбызны, кылган изге гамәл-гыйбадәтләребезне, догаларыбызны кабулллардан кылса иде.




Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа хәзрәтләре (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) үзенең мөбарәк хәдисендә: «Рамазан аеның беренче ун көнлеге – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте көннәре, икенче ун көнлеге – гөнаһлардан пакьләнү көннәре һәм соңгы ун көнлеге – җәһәннәм утыннан котылу көннәре», – дигән.

Рамазан аеның соңгы ун көне аеруча кадерле, кыйммәтле, чөнки бу айның ахырында истәлекле көннәр бар. Рамазанның 21 нче көне бөтен Ислам дөньясында билгеләп үтелә торган «Фәтех Мәккә» көне дип атала. Быел ул милади буенча 5 июнь көненә туры килә. Бу көнне сөекле Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) үзенең 12 мең сугышчыдан торган гаскәре белән Мәккәи Мөкәррамә шәһәрен дингә ышанмаган мәҗүсиләр кулыннан азат итә һәм мөселманнарның кыйбласы булган Кәгъбәтулладан табыну өчен хезмәт иткән 365 потны, таш сыннарны чыгарттыра. Шулай итеп, Фәтех Мәккә көнендә Кәгъбәтулла фәкать Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кыла торган йортка әйләнә. Фәтех Мәккә көне Ислам динендә ялганның җиңелүе, хакыйкатьнең җиңү көне булып тора.

Рамазан аеның соңгы ун көнлегендә бик кыйммәтле, мөкаддәс бер кичә бар – ул Кадер кичәсе. Мәгълүм булганча, бу изге кичәдә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Расүлуллаһ (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) хәзрәтләренә Коръән иңдерә башлаган. Аллаһы Раббыбыз бу мөбарәк кичә турында Үзенең китабында болай дип әйтә:

**«Хакыйкать шулдыр ки, Без аны (Коръәнне) Кадер кичәсендә иңдердек. Кадер кичәсенең нәрсә икәнен син беләсеңме? Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк. Ул көндә фәрештәләр вә Изге Рух (Җәбраил), Раббының рөхсәте илә, Аның әмерләрен җиренә җиткерер өчен, бер-бер артлы иңеп кенә торырлар. Кадер кичәсе – иминлек кичәсе – таң ата башлаганга чаклы дәвам итәр».**

«Кадер / Кадер Киче», 97

Бу сүрәдә Аллаһы Тәгалә барыбызга Кадер кичәсенең фазыйләтләре, өстенлекләрен, әһәмиятен күрсәтә. Кадер кичәсендә кылган изге гамәл-гыйбадәтләр өчен, хәтта бер изге сүз өчен булса да, Аллаһы Раббыбыз савапларны күпкә арттырып бирә. Әгәр Кадер кичәсендә кылган изге гамәлләрне башка айларда, кичәләрдә кылсак, андый зур әҗер-савапларга ирешә алмас идек.

Кадер кичәсенең вакыты төгәл билгеләнмәгән. Безнең хәнәфи мәзһәбе галимнәре аны Рамазан аеның 27 нче көненә каршы кич, дип белдерәләр. Ягъни быел Ләйләтүл-Кадер 10 нчы июньнән 11 июньгә туры килә, дип фаразлый алабыз.

Сөекле Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) Рамазан аеның соңгы ун көнендә игътикәф кылган, ягъни мәчеттә торып, күп гыйбадәтләр һәм догалар кылган.

Игътикәф кылып, без үзебезнең күңелләребезне сафландырабыз, йомшартабыз, Аллаһы Тәгаләгә якынаябыз. Кодси хәдистә Аллаһы Раббыбыз: «Әгәр кеше Миңа бер уч төбе кадәр якынайса, Мин аның бер кулы кадәр якынаермын. Әгәр Миңа атлап килсә, Мин аңа йөгереп килермен», – дигән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Әгәр игътикәф кылырга хәлебездән килми икән, без өйләребездә дә төнге нәфел гыйбадәтләр, истигъфарлар, догалар кылып, Кадер кичәсен каршы ала алабыз. Расүл әкрам (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Кем Аллаһка ышанып һәм савабын Аллаһы Тәгаләдән көтеп, Кадер кичәсен гыйбадәт белән уздырса, ул кешенең гөнаһлары гафу ителер», – дигән.

Әнәс (Аллаһ аннан разый булсын) риваять итә: «Мөбарәк Рамазан аенда Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) безгә болай дип әйтте: «Сезгә Рамазан ае килде, бу айда мең айдан да хәерлерәк булган кичә бар. Кем бу кичәдән мәхрүм булса, бөтен изгелекләрдән мәхрүм булыр, һәм бу кичәдән бары тик бәхетсезләр генә мәхрүм буладыр», – диде».

Нәфел гыйбадәтләрнең фазыйләте турында икенче бер кодси хәдистә болай дип әйтелгән: «Бәндә Миңа нәфел гыйбадәтләрен кылып якынаер. Мин аны яраткач, аның ишетә торган колагы, күрә торган күзе, тота торган кулы, йөри торган аягы булачакмын. Ул Миннән берәр нәрсә сораса, Мин аңа, һичшиксез, аны бирәчәкмен. Миннән яклау сораса, яклаячакмын».

Бу хәдисне галимнәр болай дип аңлаталар: Аллаһы Тәгалә өстәмә гамәлләрне, ягъни нәфел гыйбадәтләрен кылучыны Үзенә якынайта һәм аны иман дәрәҗәсеннән ихсан дәрәҗәсенә күтәрә, шуның нәтиҗәсендә кеше Аллаһы Тәгаләне күргән кебек гыйбадәт кыла башлый, аның йөрәге Аллаһка карата мәхәббәт, хөрмәт, курку белән тула. Ниһаять, Аллаһы Тәгаләне танып белү сәбәпле, ул күңел күзе белән күрә башлый. Калеб нәфес хакимлегеннән азат ителә һәм Аллаһы Тәгалә теләгәнне генә тели башлый. Шундый калебкә ия булган кеше Аллаһы Тәгаләне искә алмыйча бернәрсә дә сөйләми, Аның боерыгыннан тыш бернәрсә дә кылмый, сөйләгәндә Аллаһның ярдәме белән сөйли, караганда Раббысының ярдәме белән карый, берәр әйбер тотканда Аның ярдәмендә тота.

Мөхтәрәм җәмәгать! Кадер кичәсенең шундый билгеләре бар: ул кичә аяз була, артык суык та, эссе дә булмый, кар-яңгыр яумый, җил исми. Кадер кичәсе тын һәм нурлы була.

Газиз дин кардәшләр! Нәфескә каршы торып, Рамазанның соңгы көннәрен нәфел гыйбадәтләре, зекерләр, тәүбәләребез белән бизик, Аллаһның рәхмәтеннән, мәгъфирәтеннән мәхрүм булмыйк.

**■ Нияз хәзрәт Сабиров,**
**ТҖ МДН дәгъват бүлеге җитәкчесе,**
**Апанай мәчете имам-хатыйбы**

# Каза уразасын таләп итә торган хәлләр

1. Ашарга яраксыз нәрсәләрне йоту (кәгазь, туфрак, мамык кебек).

2. Борынга дару тамызу.

3. Колакка дару тамызу.

4. Суны очраклы рәвештә йоту, мәсәлән, авызны яки борынны чайкаганда.

5. Авызда тупланган төкерекне йотканда, аңа катнашкан чит нәрсәләрне дә йоту.

6. Уразаны бозарга мәҗбүр булганда.

7. Йоклаган кешенең тамагына башка берәү су агызганда.

8. Үз-үзеңне мәҗбүр итеп коскан чакта авызны тутырып косу.

9. Ялгышып, вакытыннан алда авыз ачу (ахшам намазының вакыты керде дип уйлап).

10. Сәхәр вакыты чыкканнан соң ялгышлык белән ризык ашау (әле таң атмады дип уйлап).

Бу очраклар уразаны боза һәм каза уразасын (көнен көнгә тутырып тоту) таләп итә.

# Нәрсә ул кәффарәт?

Әгәр Рамазан аенда ураза тоткан кеше шул эшләрнең берәрсен белә торып һәм гозерсез эшли калса:

– ашаса, эчсә яки дару капса (таблетка яки сыеклык);

– җенси якынлык кылса;

– тәмәке тартса,

аңа бозылган уразасын каза итеп, көнен көнгә тутырып тотарга кирәк була һәм ул кәффарәт үтәргә тиеш.

Кәффарәт – Рамазан ае уразасын белә торып бозган өчен бу дөньяда бирелгән җәза. Рамазан ае уразасыннан тыш башка уразаларны бозган өчен кәффарәт үтәлми.

Кәффарәт рәттән 60 көн ураза тотудан тора. Әгәр кәффарәт өзелсә, яңабаштан 60 көнлек ураза тотарга кирәк. Кәффарәт уразасы тоткан хатыннар хәез көннәрендә аны туктатып торалар һәм бу көннәр тәмамлангач, яңадан дәвам иттерәләр.

Кемнәр җитди сәбәп белән 60 көнлек уразаны тота алмый икән, 60 фәкыйрь мөселманның тамагын туйдырырга (иртәнге һәм кичке аш ашатырга) тиешләр (тәкъвалы мөселманнарны тапсаң яхшырак була). Динсез кешеләргә кәффарәт бирелми. Ризык җитәрлек күләмдә һәм сыйфатлы булырга тиеш (мәсәлән, бодай икмәге). Бер фәкыйрьгә 120 тапкыр иртәнге аш яисә кичке ашны ашатырга мөмкин. Яисә 60 кешегә иртәнге аш, 60 кешегә кичке ашны ашатсаң ярый.

Бирелергә тиешле ризыкның бәясен акчалата бирергә дә була. Бер фәкыйрьгә 60 көн буе яисә 60 кешегә бер көндә бирсәң була. Әгәр бөтен сумманы бер көндә бер кешегә генә бирсәң, бер көнлек кәффарәт кенә булып санала.

Әгәр кеше бер Рамазан аенда берничә тапкыр уразасын белә торып бозса (яки берничә Рамазан аенда уразасын белә торып бозса), бөтен очраклар өчен бер кәффарәт бирсә җитә.

Әбү Һөрайра (Аллаһ аннан разый булсын) тапшырган: «(Бервакытны) без Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) белән бергә утырганда, аның янына ниндидер бер кеше килеп шуны әйтте:

– Әй Аллаһның Расүле! Мин һәлак булдым!

– Ни булды сиңа? – дип сорады Пәйгамбәр.

– Мин ураза вакытында хатыным белән якынлык кылдым.

– Азатлыкка чыгарыр өчен колларың бармы синең?

– Юк.

– Ике ай буе рәттән ураза тота аласыңмы?

– Юк.

– Алтмыш фәкыйрьнең тамагын туйдыра аласыңмы?

– Юк.

Әбү Һөрайра (Аллаһ аннан разый булсын) болай дип сөйли: «Шуннан соң Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) бераз вакыт тын калды. Без шул хәлдә булган чакта, Пәйгамбәргә бер кәрзин тулы хөрмә китерделәр. Ул: «Сорау биргән кеше кайда?» – дип сорады.

– Мин монда, – дип җавап бирде кеше.

Шуннан соң Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын):

– Ал боларны һәм сәдака итеп тарат, – диде.

Теге кеше:

– Мин боларны үземнән фәкыйрьрәк кешеләргә өләшергә тиешме, әй Аллаһның Расүле? Аллаһ белән ант итәмен, Мәдинә шәһәрендә минем гаиләмнән дә фәкыйрьрәк гаилә юк, – дип җавап кайтарды.

Шуннан соң Пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) тешләре күренерлек итеп елмайды, аннары соң болай диде:

– Бар, бу хөрмәләр белән үз гаиләңне туендыр».

# Игътикәф

Игътикәф – Раббыбызга гыйбадәт кылу нияте белән билгеле бер вакытка мәчеттә яки башка берәр урында калу.

Әбү Хәнифә мәзһәбе буенчә, 3 төрле игътикәф була:

1. Вәҗиб игътикәф. Мәсәлән, бер кеше, Аллаһ аның нинди дә булса тәгаен теләген үтәсә, фәлән көн игътикәфтә калачакмын, дип, Аллаһы Тәгаләгә ант итсә. Бу очракта, аның әлеге теләге кабул булган вакыттан алып, игътикәф аның өчен вәҗиб була. Йә булмаса бер кеше, төгәл шартын куймыйча, билгеле көннәр санында игътикәфтә калырмын дип ант итеп, игътикәфне үзе өчен вәҗиб итә.

2. Сөннәт игътикәф. Рамазан аеның соңгы 10 көнендә башкарыла.

3. Нәфел игътикәф. Игътикәфнең бу төре өчен махсус вакыт яки билгеләнгән көннәр саны юк. Кеше үзе теләгән кадәр көнгә игътикәфтә калырга ният итә ала, хәтта бөтен гомере буена да.

Әбү Хәнифә мәзһәбе буенча, игътикәфнең дәвамлыгы бер көннән дә азрак булмаска тиеш. Игътикәф өчен бик зур савап языла, аның файдасы һәм бәрәкәте санап бетергесез.

Игътикәфтә булыр өчен иң хәерле урын – Мәккәдәге Әл-Харам мәчете, аннан кала – Мәдинәдәге Ән-Нәби мәчете, ә аннан соң – Кодыстагы Бәйтүл-Мөкаддәс.

Үз шәһәреңдәге җәмигъ мәчет дәрәҗәсе ягыннан алар артыннан килә, һәм иң соңыннан – өеңә иң якын булган мәчет. Югарыда санап кителгәннәрнең барысы ир-атлар өчен генә. Хатыннар исә игътикәфне, кайбер галимнәр фикеренчә, өйләрендә дә үткәрә ала, әмма моның өчен бүлеп бирелгән махсус урын булырга тиеш. Шул рәвешле, монысы хатыннар өчен эшләнгән бер кулайлык.

Игътикәф кылучы ирләр мәчеттә ашыйлар, эчәләр һәм йоклыйлар. Аларга бәдрәфкә бару, тәһарәт алу кебек мәчеттә үтәү мөмкин булмаган эшләр һәм аш-су алып килү өчен генә мәчеттән чыгу рөхсәт ителә.

Әгәр сәбәпсез дөнья эше өчен мәчеттән чыгып, алты сәгать вакытын читтә үткәрсә, игътикәф бозыла.

Игътикәфтәге ирләргә хатыннарының тәннәренә кул тидерү хәрам санала. Әгәр алар мәчеттән чыккан вакытларында якынлык кылсалар, игътикәфләре бозыла.

Игътикәфтәге кешеләр мәчеттә намаз, Коръән укыйлар, гыйлем өйрәтәләр һәм өйрәнәләр, зикер, тәсбихләр әйтәләр, китаплар укып, дини мәсьәләләр турында сөйләшеп утыралар. Аларга мәчеттә дөнья эшләрен башкару һәм дөнья мәшәкатьләре турында сөйләшү мәкруһ санала.

Әгәр Аллаһы Тәгаләнең әлеге бөек бүләген тиешенчә бәяли алсак, әлбәттә, без игътикәфтә калыр өчен көчебездән килгәннәрнең барысын да эшләр идек. Гомеребездә тагын ничә Рамазан аен каршы алачагын беребез дә белә алмый. Бәлки нәкъ менә бу Рамазан безнең өчен соңгысыдыр, ә аннан соң – дөньяда бөтен кылганнарың өчен хисап бирү вакыты!

■ **«Ислам дине нигезләре» китабыннан**



# VI Республикакүләм ифтар

Казан теннис академиясендә VI Республикакүләм ифтар узды. Оештыручыларның карары белән, быел ул ике көндә: 26 майда – ирлатлар өчен, 27 майда – хатын-кызлар өчен булды.

Ифтарда төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, ТР Хөкүмәте әгъзалары, депутатлар, чит дәүләтләрнең илчеләре, Татарстан һәм Россиянең төрле төбәк дин эшлеклеләре, православие һәм католик руханияте вәкилләре, шулай ук халыкның социаль яктан якланмаган катламнары: күп балалы һәм аз тәэмин ителгән гаиләләр, физик сәламәтлеге чикле кешеләр катнашты. Моннан тыш, ифтарны хөрмәтләп Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов килде.

Ифтар традицион рәвештә Коръән Кәрим сүрәләрен уку белән башланды. Республика мәҗлесендә катнашучыларга сәламләү сүзләре белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөрәҗәгать итте.

– Без Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәсәлләмнең сүзләрен искә төшерәбез: «Рамазан ае җиткәч, Җәннәт ишекләре ачыла, Җәһәннәм ишекләре бикләнә һәм шайтаннар чылбырга богаулап куела», – дип әйтте Татарстан мөселманнары башлыгы. Ягъни әлеге айны Аллаһы Тәгалә без Аңа изге гамәлләр кылып һәм тыйганнардан тыелырга омтылсын өчен әзерләгән. Ул шулай ук: «Аллаһка өмет һәм ышаныч белән Рамазан аенда ураза тоткан кешенең элекке гөнаһлары гафу ителер», – дип әйтте. Мин ихлас күңелдән Раббыбызның тоткан уразаларыбызны һәм кылган гыйбадәтләребезне кабул итүен, Рамазаннан соң чиста һәм гөнаһлардан азат хәлдә күрешүебезне телим. Ураза Аллаһы каршындагы иң сөекле гыйбадәтләрнең берсе. Һәрбер гамәл өчен савап фәрештәләр тарафыннан языла, ә ураза өчен савапны Аллаһы Үзе бирә, чөнки ул Аның өчен генә. Ә Аллаһы ризалыгына һәм Аның савабын алудан башка тагын нинди зур бүләк була ала?

Изге Рамазан аеның фазыйләтләре, ураза тоту һәм гыйбадәтләр кылу үзенчәлекләре турында вәгазь белән Татарстан мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов чыгыш ясады. Ул шулай ук чыгышында изге гамәлләр кылырга өндәде.

Авыз ачу вакыты җитү белән ифтарда катнашучылар Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә җәмәгать белән ахшам намазы укыды.

Намаздан соң катнашучылар кунаклар белән бергә сый-нигъмәтләр табынына узды. Аның төп ризыгы пылау булды. Авыз ачу менюсына киптерелгән җимешләр, җиләк-җимешләр, су, сок, пылау, өчпочмак, бөккән, чәк-чәк, конфит, печенье керә. Ашамлыкларны әзерләү өчен 1,100 тонна сыер ите, 600 кг дөге, 1,2 тонна яшелчә, шулай ук 2 тонна җиләк-җимеш, 800 кг кипкән җиләк-җимеш, 8000 чәк-чәк, 2000 литр сок, шешәләрдә 7000 литр су сатып алынган. Моннан тыш, ике көн дәвамында, Республика ифтарына билетлар җитмәүчеләр өчен, 400 ланч-бокс тарату каралган иде.

Авыз ачу чарасы тәмамлануга ук Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов журналистлар белән аралашты. Республика башлыгы Россия Президенты Владимир Путинның боерыгы белән «Россия – ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркемен җитәкләве турында искә төшерде һәм Татарстанның ислам дөньясы белән актив эшләве, күптән түгел Казанда Kazansummit-2018 халыкара икътисади форумы узу турында әйтте, анда ислам дөньясының күп илләреннән вәкилләр бар иде.

Республикакүләм ифтар турында сөйләгәндә Рөстәм Миңнеханов болай дип билгеләде: «Безнең зур масштаблы чаралар үткәрү тәҗрибәбез бар. Бу безнең традицияләр, мөселманнар ифтарга районнардан киләләр. Барысы да тынычлык һәм татулык теле. Бу безнең республикабыз һәм гомумән илебез үсеше өчен бик мөһим». Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, бүген илебездә дини хисләр һәм гражданнарның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен бар шартлар тудырылган. «Һәм без моның өчен күпмилләтле илебез җитәкчелегенә рәхмәтле», – диде ул.

Камил хәзрәт Сәмигуллин үз чыратында «республика ифтары өммәтне, татарстанлыларны һәм безнең йөрәкләрне берләштерү көченә ия» булуы белән танылуы турында әйтте. «Сез безгә башка конфессия вәкилләренең килүен күрә ала идегез. Бу, дөрестән дә, безне берләштерә, һәм без бердәмлек белән Татарстанда яшибез».

– Ифтарның максатлары күп, – дип әйтте ул, катнашучылар арасында ураза тотмаучылар булу турында бирелгән сорауга. – Бүген бирегә «бер өстәл янына» төрле мөмкинлектәге, дәрәҗәдәге, диндәге һәм милләттәге меңләгән кеше җыелды. Бу ритуал гына түгел, бу – күрешү һәм берберебезне Изге Рамазан ае белән тәбрикли алу мөмкинлеге.

РФ мөселман-эшмәкәрләр Ассоциациясе президентының беренче урынбасары Радик Абдрахманов: «Россиядә мөслимәләр өчен әлеге масштабтагы чаралар уздырылганы юк, бәлки, бөтен дөньяда да эзләп табып булмас. Әммә без киләчәктә Республикакүләм ифтарның күләмен тагын да арттырырга ниятлибез. Алдагы елларда без ир-ат һәм хатынкызларның санын билгели алмый идек. Гәрчә, алар өчен җитәрлек мәйданда намаз уку һәм авыз ачу заллары аерым кирәк булса да. Моннан тыш, Казан теннис Академиясенең техник мөмкинлекләре дә безне кеше саны ягыннан чикләп тора. Ниһаять, әгәр дә ифтар кушылып уздырылган булса, намазны урамда укырга туры килер иде, ә һава торышына ышаныч юк. Иң мөһиме: хатын-кызлар ирлатлардан башка үзләрен иркенрәк һәм уңайрак тоя, махсус программаны күзәтә, иптәшләре белән аралаша. Без мөслимәләргә шундый бәйрәм ясарга теләдек!» – дип билгеләде.

Ифтарның беренче көне тәгәлләнгәч, Камил хәзрәт Сәмигуллин традицион рәвештә волонтёрлар десанты белән очрашты. Ул аларга тырыш хезмәтләре өчен рәхмәт белдерде: «Кешеләргә рәхмәтле булу турында Аллаһ Илчесе саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтендә әйтелә. Чөнки хәдистә әйтелгән: «Кешеләргә рәхмәтле булмаган, Аллаһка да рәхмәтле була алмый». Бу хәдис кешеләргә рәхмәтле булуның Аллаһка рәхмәтле булу икәнлеген күрсәтә, бу теге яки бу кеше Аллаһның ихтыяры белән ярдәм күрсәтүдә арадашчы булган, ягъни әлеге кешене Аллаһ ярдәм итү мөмкинлеге белән бүләкләгәнен аңлата. Икенче бер хәдистә Аллаһ Илчесе саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә, «Рамазан аенда ураза тотучыны ашаткан кеше ураза тоткан кадәр савап алыр, ураза тотучының савабын киметмәс. Ин шә Аллаһ, сез бүген ифтарга килгән һәрбер ураза тотучыдан савап алдыгыз. Хезмәтләрегез һәм тырышлыкларыгыз сезгә савап булып языл-сын!»


Ифтар кунакларын каршы алу, җәмәгать намазын укуны оештыру, ашамлыкларны бирү һәм ифтардан соң җыештыру өчен 16 яшьлек һәм аннан өлкәнрәк 325 волонтер җәлеп ителде.

■ dumrt.ru





# VI Республикакүләм ифтар









# Яңа өйдә дога кылу

**Сорау: Мөселман яңа өй салып керә һәм Коръән укырга чакыра. Мин үзем өйдә азан әйтеп, 1-2 сүрә укыйм. Шулай дөресме, яки нинди дога уку яхшырак?**

**Җавап:** Мөселман кеше яңа өй салып керә икән, бу – шатлык. Шул шатлыгын уртаклашыр өчен үзенең якыннарын, дусларын чакырып сыйлый. Ә инде мөселманнар җыелганда Аллаһны зикер итәләр. Аллаһ сүзе булган Коръән китабын укып, аны кешеләргә аңлатып китсәләр, нур өстенә нур, ягъни яхшы була. Ләкин, һичшиксез, Коръән укытуны тиеш, фарыз дәрәҗәсендәге шәригать таләбе итеп карау дөрес түгел. Шулай ук бу очракта укырга тиеш булган махсус аять-сүрәләр дә юк. Ә инде сүрә укыргамы яки дога укыргамы дигәндә, алар икесе ике нәрсә. Матур итеп мөселман кардәшләреңне хөрмәт иткәч, яхшы вәгазьләр сөйләнгәч, арадан бер галимрәк, тәкъварак кеше дога кылса, ин шә Аллаһ, хәерле булыр.

# Яулык өстеннән мәсех кылынамы?

**Сорау: Берәүләр яулыксыз, икенчеләр яулык, оек өстеннән мәсех кыла. Кайсы дөрес?**

**Җавап:** Яулык өстеннән мәсех кылынмый. Әгәр кемдер Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен намаз укый, аның кабул булуын тели икән, аяк юарга бер-ике минут вакыт тапмыймы? Бер-ике минут вакыт иренеп, ул намазын кабул булмаслык хәлгә китерә. Шуның өчен «үзеңне шикләндергән нәрсәдән шикләндермәгән нәрсәгә күчереп куй», –дигән Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын). Мәсехне нәрсәгә кылырга була – болар китапларда күрсәтелгән. Мисал өчен, моңа күн читек керә.

# Малайларны кайчан сөннәткә утыртырга кирәк?

**Җавап:** Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әйтүе буенча, бала туып 7 көн үткәчтен сөннәткә утыртыла. Ләкин соңрак башкарылса да була.

Мутла каласында (Төркия) 25 ел бабачылык иткән Исмәт Дурал сөннәт өчен иң кулай чор – яшь ярымга хәтле, дип саный, тик кайбер гаиләләрдә хәзер бу эшне соңлата башладылар, ди. «Сөннәткә утырту өчен иң кулай һәм файдалы чор – сабый чакта. Инде ул вакыт узган икән, бала эшнең асылын аңлый башлагач кына сөннәтләндерергә кирәк. Яше тулганчы сөннәтләндерелгән баланың җәрәхәте тиз төзәлә, тәне азгын булмый. 3-5 айлык сабыйга, иң соңы – 1-1,5 яшьләр арасында бу операция җиңел кичерелә. Бу чорда бала авыртуны артык нык тоймый, сөннәттән курку тойгысы да аңа әле таныш түгел. 1,5 яшьтән соң бала уколдан, каннан курка башлый. Яшь ярымга хәтле сөннәтләнми калган баланы 6-12 яше тулгач кына сөннәткә бирегез, чөнки бу яшьтә инде балалар эшнең асылын аңлый башлый. Мәсәлән, бу яшьтәге 100 баланың нибары икесе генә куркып елый башлый», – дип аңлата тәҗрибәле бабачы.

Исмәт Дурал сөннәтнең әһәмиятен бөтен дөнья аңлый башлады, ди. Гигена күзлегеннән чыгып, хәзер инде шифаханәләрдә малайларга операцияне хирург ясый. Сөннәтләнгән малайлар өч көннән соң аякка басып, гадәти тормыш белән яши башлый.

# Күз тиюгә каршы тәнгә әйбер тагу дөресме?

**Җавап:** Күз тию күренешен инкяр итеп булмый. Аның барлыгы катгый исбат ителгән. Ләкин күз тиюне булдырмау өчен тәнгә төрле әйбер тагып йөрү – хаталы эш. Әлбәттә, тәннең (киемнең) кайсы җирендә булса да ялтыравыклы яки башка шундый күзгә бәрелеп тора торган әйберне тагып, «кешенең игътибары шул әйбергә тартылып, күзе тимәс» дигән ышануларга нигезләнгән. Бу ысул белән балаларны явыз күздән сакламакчы булалар. Хәлбуки, күз тиюгә каршы иң яхшы чара һәм дәва – Коръән Кәримнән сүрәләр уку. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) һәм аның сәхабәләре заманында бу ысул уңышлы кулланылганы мәгълүм. Гадәттә, күз тиюгә каршы «Фәтихә», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс» сүрәләре, «Аятел-Көрси» һәм «Каләм» сүрәсенең 51 нче аяте укыла.

# Мөнәҗәт әйтергә ярыймы?

**Сорау: Аш мәҗлесләрендә мөнәҗәт әйтергә ярыймы, аларны көйләп уку рөхсәт ителәме?**

**Җавап:** Хатын-кызлар аерым үткәргән мәҗлестә эчтәлеге шәригатькә каршы булмаган, музыка кораллары кулланмыйча, мәҗлестә катнашучыларда динебезгә мәхәббәт тәрбияләү ниятеннән мөнәҗәтләр әйтү мөмкин.

# Шәригать бәян иткән гамәлләр

**Сорау: Конкрет мисаллар китереп (гади халыкка аңлаешлы итеп), вәҗиб, сөннәт, мөстәхәб, мөбах, мәкруһ, хәрам гамәлләренә аңлатма бирсәгез иде. Мәгънәсен дә бирсәгез иде.**

**Җавап:** Бу хакта «Гыйбадәте Исламия»дә ачык бәян ителә. Болар, нигездә, шәригать, ягъни кешеләрнең гамәлләре хакында Ислам дине тарафыннан боерылган хөкемнәргә карый. Аларны белү һәр мөселман кешегә фарыздыр.

Фарыз (гарәпчә – бурыч, мәҗбүри) бер эшне үтәү мәҗбүри, аны эшләмәгән мөселман җәһәннәмдә җәза ала, ә фарыз эшнең мәҗбүрилегенә ышанмау көферлек санала.

Фарыз ике төрле була:

(а) фарыз-гайн, ягъни һәр мөселманның үзе кылырга тиеш, аның өчен бүтәннәр эшли алмый торган фарызлар: биш вакыт намаз, ураза, җомга намазы һәм зәкәт һ.б.;

б) фарыз-кифая – бер мөселман кылганнан соң башкаларның бу җаваплылыктан азат ителүе: җеназа намазы, җәмәгатьтә сәлам алу һ.б. Әгәр мондый эшне беркем дә эшләмәсә, мөселманнарның барысы да җаваплы, бурычлы булып кала.

Вәҗиб (гар. – кирәкле, зарури) – шулай ук мәҗбүри санала торган эш, гамәл, аны кылган кеше саваплы булыр, кылмаган кеше – гөнаһлы. Вәҗиб гамәлләр: витр һәм бәйрәм намазларын уку, фитыр сәдакасы бирү, корбан чалу һ.б. Ләкин аны эшләмәгән өчен җәза бирелми.

Сөннәт (гар. – гадәт, йола) – хуплана торган, саваплы эш, ләкин аны эшләмәү гөнаһ түгел. Әмма эшләмәгән кеше Мөхәммәд галәйһиссәләмнең шәфәгатенә лаек булмас. Сөннәт гамәлләр: яхшы гамәлләрне «бисмиллаһ» илә башлау, Коръән укыр алдыннан «әгүзе» әйтү, төчкергәч «әлхәмдүлилләһ» дию, иманлы кешегә сәлам бирү һ.б. Пәйгамбәребез сүзе вә эше, гамәле, хуп күргән, макталган эш-гамәлләре сөннәт. Сөннәт тә икегә бүленә: а) сөннәте-мөәккәдә, ягъни Пәйгамбәребез дәвамлы эшләп, сирәк очракта гына калдыра торган сөннәтләр; б) сөннәте-гайри-мөәккәдә, ягъни Пәйгамбәребез аратирә кылган сөннәтләр (гамәлләр).

Мөстәхәб (гар. – гүзәл, яхшы) – аны кылган кеше саваплы булыр, кылмаган гөнаһлы да булмас. Ул гамәлләр: нәфел намазлары уку, нәфел уразалары тоту, нәфел сәдакалары бирү, буш вакытта Коръән уку һ.б.

Мөбах (гар. – рөхсәт ителгән) – эшне үтәгән өчен савап та юк, үтәмәү дә гөнаһ түгел. Пәйгамбәребез кайчак кылырга яраткан эш-гамәлләрдер. Утыру, тору, зарарсыз сүзләр сөйләү, хәләл нәрсәне туйганчы ашау.

Хәрам (гар. – тыелган) – катгый тыелган эш, аны эшләүче кеше тәмуг җәзасына лаек санала, тыелганны инкяр итү (кире кагу) көферлек.

Мәкруһ (гар. – шелтәләнә торган) – тыелган эш, аны кылган кеше гөнаһлы булыр, аны дөрес дигән кеше дә гөнаһлы. Бу гамәлләр: отышлы уеннар уйнау, әдәпсез җырлар җырлау, кеше алдында әдәпсез кылану һ.б.

Мөстәкраһ (гар. – җирәнгеч, начар) – аны кылган кеше гөнаһлы булмаса да, әдәпсезлек кылган булыр. Бу гамәлләр: базарда һәм урамда ашау, авызны капламыйча иснәү, кычкырып кикерү һ.б.

■ **Сәхифә Г. Саматовның «Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр» китабы буенча әзерләнде**

# Кыямәт көнендә биреләчәк сораулар

Бөтен дөньяда яшәгән мөселманнар хаҗ кылудан, Коръән укудан, Аллаһка гыйбадәт кылудан туктамыйча торып, Кыямәт көне җитмәячәк. Дөнья бетүе, Кыямәт җитүе хакында нинди генә фаразлар юк. Гасырлар дәвамында бу хакта бәхәсләр яшәп килгән. Кемдер майя халкы төзеп калдырган календарьга таянып, 2012 елда дөнья бетәчәген көтте. Олырак буын вәкилләре бәлки 1982 елда булган шуңа охшаш вакыйгаларны хәтерлидер. Иң кызыгы шул: җәмгыятьтә мондый ажиотаж билгеле бер вакыт аралыгы саен даими рәвештә кабатланып тора. Эш нәрсәдә соң? Кемдер махсус рәвештә кешеләрне куркуга саламы яисә башка сәбәп бармы…

Без белергә тиешле булган нәрсә: Кыямәт көнендә бары тик мөселманнар гына котыла алачак. Нәкъ менә Ислам дине кешеләргә киләчәккә ышаныч уята. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әйткән булган: «Әгәр иртәгә Кыямәт көне булачак дисәләр, һәм синең кулыңда агач үсентесе булса, аны утырт». Татарларда: «Күчеп китсәң дә, чәчеп кит», – дигән мәкаль бар. Әлбәттә, өметне өзеп, кул кушырып утырырга ярамый. Тырышып эшләгән, гаиләсенең һәм якыннарының тормышын кайгырткан кешегә һәр яңа туган көн яңа өметләр алып килә.

## Кыямәт көнендә безне ниләр көтә соң?

– Кешеләр каберләреннән кубарылыр. Моңа ышану бик кыен, әлбәттә. Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгаләгә күп кеше ышана. Аллаһка да, Аның Китапларына һәм пәйгамбәрләренә дә ышанырга мөмкин, ләкин кешеләрнең каберләреннән кубарылачагына, үлгәннән соң кабат терелүгә ышану бигрәк тә авыр. Ләкин бу бик мөһим, чөнки бу дөнья вакытлы бер йорт кына, алда безне мәңгелек тормыш көтә. Моны аңлар өчен, әйдәгез, шундый мисалны күз алдына китерик. Әйтик, бу дөнья тормышы поездда бару кебек бер сәяхәт кенә, ди. Мәсәлән, поезд Казаннан Мәскәүгә юл тота. Кемдер купеда, кемдер плацкарт вагонында, кемдер бөтен кеше белән бергә гади вагонда сәяхәт итә. Җыеп әйткәндә, һәркем кесәсенең калынлыгына карап билет сатып алган. Ләкин шул ук вакытта һәркемнең барачак урыны билгеле, барысы да бер урынга бара.

– Ахирәттә безне мәңгелек гадел тормыш көтә. Кыямәт көнендә кешенең кылган барлык гамәлләре ачылачак, изгелекләре һәм явызлыклары Мизанга салып үлчәнәчәк. Кыямәт көнендә җир йөзе тетрәр, күкләр ярылыр, йолдызлар коелып төшәр, таулар ишелер. Бөтен тереклек үлеп бетеп, 40 ел үткәч, җир йөзе кабат терелә башлар. Җир өсте тигез булыр, кешеләр каберләреннән кубарылыр. Җаннар кабат үз тәннәренә кайтырлар. Шул көннән башлап мәңгелек тормыш башланачак. Ул көнне кем Аллаһның рәхмәте астында булыр?

– Кыямәт көнендә һәркемгә биш сорау бирерләр: Намаз укыдыңмы? Яшьлегеңне ничек үткәрдең? Тормышыңны нәрсәгә багышладың? Нәрсәләр кәсеб иттең һәм тапкан малларыңны кая сарыф иттең? Гыйлемеңне һәм һөнәреңне ничек кулландың?

Бу сорауларны һәркем үзенә даими рәвештә бирергә тиеш.

# Кыямәт көнендә Пәйгамбәребезгә иң якын кешеләр



Хикмәт ияләре Пәйгамбәребезгә (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) салават әйтүнең фазыйләтләрен түбәндәгеләрдә күрделәр:

Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә Адәм каршында сәҗдә кылырга кушкач, фәрештәләр Адәмне Мөхәммәдтән өстен дип уйлап куйдылар. Әмма Аллаһы Тәгалә:

– Мин сезгә Адәмгә сәҗдә кылырга кушсам да, Мин Үзем шәхсән Үземнең яраткан бу бәндәмә салаватлар әйтәм һәм сезгә дә шулай ук салаватлар әйтергә боердым. Шуңа күрә Мөхәммәднең нинди бөек дәрәҗә әһеле икәнен белегез. Сез Адәмгә сәҗдәне нибары бер тапкыр гына кылдыгыз, ә салаватларны Минем яраткан колыма Кыямәт көненә кадәр әйтәчәксез.

Бөек Аллаһ беркемгә дә мохтаҗ түгел, Ул бар тереклекне барлыкка китерде һәм бар нәрсә Аңа мохтаҗ. Шушындый халәтендә дә Ул Пәйгамбәребезгә салаватлар әйтә. Ә без барыбыз да аның шәфәгатенә мохтаҗбыз һәм Кыямәт көнендә аның игътибарына лаек булырга омтылабыз. Бу тормышка ашсын өчен, әлбәттә, салаватлар әйтүдә бер генә мизгелне дә ычкындырмаска кирәк.

Фәрештәләр Пәйгамбәрне (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) яхшы белгәнгә генә аңа салават әйтмиләр. Җаһилият чорында, Мөхәммәдкә пәйгамбәрлек иңгәнче, бар җиһан бозыклыкка баткан, имансызлык изүе астында иде. Мөхәммәд пәйгамбәр булып килгәч, дөнья бу бозыклыктан чистарына башлады. Моның әҗер-савабы итеп фәрештәләргә Мөхәммәдкә салават әйтү йөкләнде.

Кешелек дөньясы барлык кайгылардан арына алмаган кебек, фәрештәләр дә аларны шайтаннар язмышы көтәр дип, бик хафаландылар. Әмма Аллаһы Тәгалә аларга бу турыда уйламаска, борчылмаска кушты һәм күп итеп салаватлар әйтергә боерды. Бу әмерне үтәгән өчен фәрештәләр һәрбер төрле кайгыдан азат булдылар.

«Зуһрурияд» китабында мондый хәдис тапшырыла: Беркөнне Җәбраил галәйһиссәләм пәйгамбәрләрнең солтаны булган Мөхәммәд янына килеп болай диде:

– Бүген мин Каф тавы артында бер сәер очракка тап булдым. Элегрәк мин күкләрдә бик тә ихтирамлы, мәһабәт бер фәрештәне күрә идем. Ул тәхетендә утырып торганда, каршында 70 мең фәрештә аңа хезмәт итәргә әзер булырлар иде. Һәм Аллаһы Тәгалә аның һәрбер сулышы вакытында бер фәрештә барлыкка китерә иде. Менә шул фәрештәне мин тау артында күрдем. Күкрәге дә, канатлары да янган, үзе үкси-үкси елый иде. Мин аннан аның хәләте турында сорадым һәм ул:

– Мигъраҗ вакытында мин тәхеттә утырып тора идем. Пәйгамбәр минем янымнан үтеп китте, әмма мин аңа тиешле хөрмәтне күрсәтмәдем. Һәм шуннан соң мин шушы бәлага тарыктым. Йә, Җәбраил, Аллаһ каршында миңа шәфәгать кылчы, – диде.

Җәбраил дәвам итеп:

– Йә, Расүлуллаһ, мин Аллаһ каршында баш иеп, Аннан ошбу фәрештәне кичерүен сорап ялындым.

Бөек Аллаһ миңа:

– Йә, Җәбраил, ул фәрештә ярлыкауны теләсә, башта Мөхәммәдкә салават җиткерсен. Һәм шуннан соң Минем ярлыкауны табар вә кабаттан Миңа якын булыр.

– Йә, Расүлуллаһ, ул фәрештә шулай эшләде дә: ул сезнең хөрмәткә салават әйтте. Аның канатлары үз халәтенә кайтты һәм үзе дә күктәге урынына менде.

Өммәтебезнең Пәйгамбәргә салават әйтүнең сәбәбенә килгәндә, югарыда әйтеп китүебезчә, Кыямәт көнендә аның шәфәгатен өмет итү. «Рияз Әнистә» китабында: «Аллаһ Үзе яраткан бәндәсен, ягъни Мөхәммәдне шәфәгатьче итеп кылды. Ә салаватларны аның шәфәгатенә сәбәп итте».

Димәк, Кыямәттә Пәйгамбәребезнең шәфәгатенә ирешер өчен, аны нык итеп яратырга тиешбез. Ә аның өчен салаватларны күп итеп кабатларга, аның сөннәтенә чын күңел белән иярергә кирәк. Менә шуңа күрә дә Мөхәммәд пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Миңа салаватларны күп итеп әйтүче Кыямәт көнендә миңа иң якын кешеләрдән булачак», – дип әйткән.

■ Islam-Today сайты

# Бәхетле мөселман гаиләсен ничек төзергә?

Соңгы елларда яшь мөселман гаиләләрендә аңлашылмаучанлык – еш күзәтелә торган хәл. Ни өчен хәзерге заман гаиләләре шундый кыска гомерле? Гаилә тормышында нинди проблемалар очрый? Ничек ул низагларны урап үтәргә? Бу хакта фикерләре белән тәҗрибәле педагог, психолог **Гөлфия Әнвәр кызы Гайнетдинова** бүлешә.

### «Гаиләдә бәхетле булыр өчен гыйлем алырга кирәк»

***– Гөлфия Әнвәровна, һөнәрегез, укыту тәҗрибәгез турында сөйләп китегезче.***

– Мин 2008 елдан башлап яшь мөслимәләр өчен курслар алып барам. Ниятем – кызларны гаилә тормышына әзерләү. Яшьләр югары уку йортларында күп фәннәр өйрәнәләр, галим булырга омтылалар, әмма уку йортларында ничек гаилә корырга дигән сорауга җавап бирмиләр. Шуңа күрә минем башымда сорау туды: «Бу балалар гаилә корырга әзерме икән?» Бу соравыма җавап эзләп, университетлар тәмамлаган яшьләр белән әңгәмәләр кора башладым. Күбесе йә башын аска иеп, оялып, сорауга җавап кайтара алмый, йә әйтергә сүзләре генә юк. Кайберләре: «Әти-әни мисалында гаилә корачакмын», – дип әйтәләр иде. Аллаһ ризалыгы белән, 2008 елда кызларны җыеп, булачак хатын/әниләр өчен курслар башладым. Кызлар кич көне укудан соңмы, эштән соңмы курсларга белем алырга йөгерәләр иде.

Үз-үземә «Кызларга тормышта нәрсә кирәк?» дигән сорау биреп, әкренләп программалар төзеп укыта башладым. Белгечлек, укытучы, табиб булып, инженер булып эшләр өчен күпмедер укырга кирәк. Шунсыз беркем дә эшли алмый. Укытучы врач булып эшли алмый, врач – укытучы булып, ягъни аның серенә төшенергә кирәк. Ә гаилә? Гаилә сиңа гомерлек. Гаилә күп тармаклардан, мөнәсәбәтләрдән тора: ирең белән, кайнанаң белән, балаларың белән һ.б. Бу искиткеч катлаулы, гыйлем сорала торган даирә. Укымыйча, гаилә кору серен өйрәнеп булмый.

Яманлыкны нәрсә китереп чыгара? Гыйлемсезлек. Аллаһы Тәгалә иң беренче гыйлем алырга куша. Белмәү аркасында күп фетнәләр килеп чыга. Гаиләдә бәхетле булыр өчен гыйлем алырга кирәк.

### «Яшьләр бер-берсен яхшылап белмичә өйләнәләр»

***– Сезнеңчә, ни өчен соңгы елларда мөселманнар арасында талак бик гадәти хәл булып китте?***

– Курслар алып бара башлагач, кызларның проблемалары килеп чыга башлады, шуларны да хәл итәргә тырышабыз. Һәм инде мин әлеге вакытта гаилә консультанты булып эшлим. Күп гаиләләр килә: аерылганнар, 2-3 балалы йә баласыз, яки күптән түгел өйләнгәннәр. Без инде әңгәмәләр төзеп, гаилә эшендә килеп чыккан проблемаларны чишеп, гаиләне саклап калу өстендә эшлибез.

Соңгы елларда мөселманнар гаиләләрендә аерылулар бигрәк күп. Нәрсә сәбәп булып тора? Яшьләрнең ата-аналар белән уртак тел тапмавы. Ешрак килен белән кайнана мөнәсәбәтләре бозылу, туганнар белән аралаша һәм килешә белмәү, кызның әнисе белән уртак тел тапмау. Шул проблемалар нигезендә аерылулар күренеп тора.

Хатын белән ир арасындагы интим мөнәсәбәтләр проблемалары еш кына талакка илтә. Шуңа күрә кызларга Коръәнгә, Пәйгәмбәребез хәдисләренә һәм дә тәҗрибәгә таянып, курсларда интим мөнәсәбәтләр хакында да гыйлем бирелә. Бу нечкә темаларны белү бик мөһим. Боларны белмәү яманлык китереп чыгара.

Яшьләр бер-берсен яхшылап белмичә өйләнәләр. Танышалар, ошыйлар, никах укыталар, егетнең эше һәм квартирасы бар, әмма ләкин гаилә килеп чыкмый. «Холыкларыбыз охшаш түгел» дип акланалар. Бу аерылган кыз һәм егетнең тагын өйләнәселәре бар, киләчәк гаиләдә дә шундый ук проблемалар туачак. Яшьләр шуны аңламый.

### «Хатыным намаз укымый, яулык бәйләми»

***– Еш кына мөселман егетләре намаз укымаган, яулык бәйләмәгән кызларга өйләнә. Киләчәктә исламга килер, дип өйләнгән егет хатынын ничек тә намазга бастырырга тырышып та, бер нәрсә дә килеп чыкмаса, нәрсә эшләргә егетләргә?***

– Бу сәбәп буенча хатынын аерган очраклар тәҗрибәмдә бар. «Хатыным намаз укымый, яулык бәйләми», дип еш кына мөрәҗәгать итәләр егетләр.

Мөселман егетләренең диндә булмаган кызларга өйләнүе гадәти хәл. Егет кешеләргә хатынын намаз укырга, яулык бәйләргә өндәү өчен бер коралга ия булырга кирәк. Ул – йомшаклык. Пәйгәмбәребез дә кешеләргә карата йомшак, түбәнчел, мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Ир-ат әкрен-әкрен өйрәтеп, хатынына һәр эштә дә ярдәм итсә, теләгәне кабул булырга мөмкин. Катылык белән, ультиматумнар куеп, кешене бернәрсәгә дә өйрәтеп булмый. Әмма Аллаһы Тәгалә безнең йөрәкләрне, күңелләрне ачучы, Ул теләсә генә, теләгәнебез кабул була. Шуңа күрә бу мәсьәләне бер кысаларга гына кертеп карап булмый, дигән нәтиҗәгә киләм. Йомшаклык белән өйрәтү нәтиҗә бирми калмыйдыр дип беләм.

### «Холкыбыз килешми»

***– Гадәти күренеш: нихахтан соң кыз белән егетнең холыклары килешмәгәне беленә. Бер-берсен аңламыйлар. Бу хәлне чишеп буламы?***

– Никахтан соң килешмәүләр, аңлашылмаучылыклар килеп чыга. Моның сәбәбе никахка дөресенчә әзерләнмәү. Танышканда, беренче чиратта кыз вә егет бер-берсен тышкы кыяфәт буенча ошаталар. Пәйгәмбәребез хәдисендә: «Бар һәм кара», – дип әйтте. Өйләнергә ниятең булгач, кызны күрергә тиешсең. Тышкы кыяфәтләрен ошаткач, яшьләр бер-берсен өйрәнә башлыйлар. Исламда булачак ирең вә хатының турында күбрәк мәгълүмат җыярга кирәк: күршесеннән, туганыннан, дустыннан һ.б. Кызның һәм егетнең гаиләсендә ата-ана һәм балалары арасында мөнәсәбәтләр нинди, нинди гореф-гадәтләре бар – барысын да белергә кирәк. Белми чыгучыларның гаиләсе бигрәк тиз таркала: хәтта өч атна гына никахлашып торганнар да бар.

Икенче яктан, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясен белмәү яшь гаиләдә тиргәшү һәм аерылу сәбәбе булып тора. Ирләр хатын-кызларны белмиләр, хатыннар – ир-атны: алар бер-берсен бер үлчәүгә куеп чагыштыралар. Дөреслектә, ирләр бөтенәй башка кешеләр, безнең капма-каршыбыз. Хатын-кыз – эмоцияле, ир-ат – кыска сүзле, акыл иясе. Ирләр психологиясен өйрәнү хатын-кызга бик кирәкле, ул мәсьәлә безнең укыту программасында да бар.

Никахтан соң ир белән хатынның беренче бурычлары нинди? Алар берберсенең холкын белергә тиеш, нәрсә белән кызыксына, нәрсә ярата яки яратмый. Яраткан кешеңнең яратмаган әйберләрен эшлисе килми. Бу мөнәсәбәтләрдә ачыклык, ихласлылык булырга тиеш, бер-береңне хөрмәт итү, бер-береңә юл кую, сабыр итү. Беренче көнне үк «Син нәрсәләр яратмыйсың?» дип сорау бирергә кирәк тормыш иптәшеңә. Моны ачыклап тормышны башлау фетнәләрдән саклый.

Никахка бик җиңел карау, сабыр итмәү, бер-береңә юл куймау аерылуга илтә. Әгәр кеше гаилә корыр алдыннан курслар үтеп, китаплар укып гыйлем ала икән, никахлашу мәсьәләсенә җаваплы карый. Аерылу бик җиңел нәрсә, әмма аннан соң нәрсә булуын белү бик авыр. Бер тапкыр кияүгә барган яки өйләнеп аерылган кешегә пар табу нык авыр, үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм.

Егет вә кыз ике төрле җирдә үскән гөл кебек. Икесе ике төрле тәрбия алган, ике төрле гаиләдә үскән, ике төрле гореф-гадәтләр белән үскән. Алар берничек тә бер төсле була алмый. Бар үзенә тиң кеше. Егет белән кыз беренче очрашканнан соң ук «Бу минем кешем» дип әйтәләр. Үзеңә туры килгән кешене йөрәк аңлый, күңел сизә. Ә менә тиз арада өйләнәшеп, тиз арада «холык килешмәде» дип аерылышу – бу, мин әйтер идем, җавапсызлык. Чөнки егет вә кыз бу дөнья өчен генә түгел, җәннәттә дә бергә булырга дип өйләнергә, ният кылырга тиеш.

Никахка шаһитләр сайлау мәсьәләсенә дә хәзер бик җиңел карыйлар. Никахта ике яктан шаһит булырга тиеш. Коръәндә әйтелә: шаһитләр булачак гаиләнең яхшы булуы өчен, бәхетле булулары өчен җавап тоталар. Шаһитләрне бик белемле, тәҗрибәле, ике яшь кешегә киңәш бирә алганнарны сайларга кирәк. Бу мәсьәләгә аерым бер игътибар кирәк.

### «Үзләре арасында булган серләрен, проблемаларын читкә чыгармаска тиеш»

***– Яшь мөслимәләр арасында еш килеп чыга торган сорау – ирнең әти-әнисе белән яшәү яшь гаилә өчен хәерлеме?***

– Әти-әни белән яшәгәндә проблемалар була, дип курка яшьләр. Алар үзләре арасында булган серләрен, проблемаларын читкә чыгармаска тиеш, чөнки алар икенче бер гаилә. Әти-әнигә дә нык гыйлемле булырга кирәк. Алар ягыннан яшьләрнең тормышына артык кагылу, төпчену дөрес түгел. Чикләр булырга тиеш. Ике гаилә арасында чикләр сакланган очракта икесе дә тату яшәячәк. Бергә аралашу әдәбе булырга тиеш. Әтиәни белән яшәгәндә гаилә, киресенчә, тату була: олылар һәрчакта булышалар, киңәш бирәләр. Әдәп һәм дини белемнәре булган олылар вә яшьләр арасында аңлашылмаучанлыклар һәм низаглар булмый.

Нәтиҗә буларак әйтәсем килә: гыйлем алыгыз. Ул һәр мөселман өчен дә фарыз. Белемле, тәрбияле кешенең башка кешеләр белән мөнәсәбәтләре һәрчак яхшы була. Гаилә корганда дин гыйлеме генә җитәрлек түгел, хатын-кыз һәм ир-ат психологиясен белү, хатын вә ирнең бер-берсен яхшы өйрәнү бик мөһим.

■ **Әңгәмәдәш Айгөл Минһаҗева, РИИ студенты**

# Рамазанда имтихан бирүчеләргә 6 киңәш

Рамазан аенда мөселманнар аеруча күңел күтәренкелеген хис итә, әмма куркып калучылар да юк түгел. Бигрәк тә ураза озын җәйге көннәргә туры килгәндә. Әмма ураза тоту авыру халәте түгел, киресенчә, бу – яңа рухи һәм физик мөмкинчелекләр. Һәр Рамазан саен Аллаһы Тәгалә безгә Үзенең ярдәмен биреп тора, күп саваплар белән бүләкли. Шул сәбәпле, ураза вакытында гадәттәгечә эшләсәк, укысак та, безнең халәтебез үзгә – безнең өчен фәрештәләр дога кыла, Раббыбыз догаларны кабул итә.

Бу вакытта кыенлыклар туса, Аллаһ безгә һичшиксез җиңеллек биреп, уразабызны тиешенчә тотып бетерергә ярдәм итәчәк. Быел Рамазан вакытына имтиханнар чоры туры килә, без имтихан тапшыручылар өчен берничә киңәш тупладык. Имтиханга яхшылап әзерләнүдән тыш, ураза тотучы укучыга түбәндәгеләрне эшләү файдалы булыр:

1. Имтиханга әзерләнүне планлаштыру, авыр темаларны акыл эшчәнлеге продуктив булган вакытка калдыру. Мисал өчен, аларны ифтар һәм сәхәрдән соң 40-60 минут үткәч өйрәнү. Тестларны биремнәрне башкаруны көннең башка вакытына күчерергә була.

2. Сезгә материалны бергәләшеп үзләштерерү уңайлырак булса, моның өчен ураза тотучы төркемдәшләрегез һәм курсташларыгыз белән берләшегез.

3. Көн дәвамында йоклап алырга тырышыгыз. Мондый ял, кыска гына булса да, организмның бик күп вазифаларына, акыл эшчәнлегенә уңай тәэсир итә.

4. Саф һавада йөрү, салкынча душ керү – ми эшчәнлеген яхшыртып җибәрер, физик яктан да файда китерер.

5. Дөрес туклану. Сәхәр вакытында файдалы һәм туклыклы ризыкка өстенлек бирү: ботка, сыр, балык, бавыр һәм ит, яшелчәләр һ.б. Ифтар вакытында артык ашамаска, майлы, тозлы ризыклардан баш тартырга. Эчемлекләрдән өйдә эшләнгән соклар, кефир, яшел чәй, газсыз чиста су сайларга. Баллы ризыкларны бал, җимешләргә алыштырырга.

6. Имтиханнарга әзерләнү дәверендә 5 вакыт фарыз намазлардан кала өстәмә (нәфел) намазлар укырга, Коръән укырга, зикерләр әйтергә һәм Аллаһка догалар белән мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Мондый догалар киңәш итәргә мөмкин:

– теләгән нәтиҗәләргә ирешү өчен – Адәм һәм Хаува (аларга Аллаһның сәламе булсын) догасы. «Әгъраф / Пәрдә» сүрәсенең 23 нче аяте, «Раббәнә...» сүзләреннән башлап, аятьнең ахырына кадәр.

– Мөһим эшләрне башлар алдыннан – «Кәһф / Тау куышы» сүрәсенең 10 нчы аяте, «Раббәнә этинә...» сүзләреннән башлап, аятьнең ахырына кадәр.

– Кыенлык килгәндә укыла торган – Юныс пәйгамбәр догасы. «Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр» сүрәсенең 87 аяте, «Лә иләһә иллә Әнт...» сүзләреннән башлап, аятьнең ахырына кадәр.

Шулай ук имтихан чоры интеллектуаль тырышлыктан кала Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлли беленү дә таләп итә. Кеше үзеннән торганын эшләп (безнең очракта имтиханнарына әзерләнеп), нәтиҗәсен Аллаһка калдырырга, Аннан гына ярдәм сорарга тиеш. Ниятләр ихлас булып, тырышлык куелса, Аллаһы Тәгалә колының догасын җавапсыз калдырмас. Бигрәк тә ул уразада булганда.

■ **Гүзәл Ибраһимова,**
**Islam-Today**

# «Бер көндә белем алу мәктәбе»

Март–май айларында Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге һәм Казанның актив мөселман яшьләре оештырган «Бер көндә белем алу мәктәбе» («Школа одного дня») проекты эшләп килде. «Мәктәп» Ислам дине белән кызыксынган һәркем өчен ачык иде. Әлеге курсларда якшәмбе көннәрне 12-60 яшьлек йөзгә якын кеше намаз уку тәртипләре һәм ислам дине нигезләре буенча белем алды.

Курсның программасы түбәндәге дәресләрдән гыйбарәт булды:

1 дәрес: «Кереш өлеше»: нәрсә ул ислам, аның нигезләре, шәригать кануннары, тәһарәт һәм госелне ничек алырга, мөселманнарның тышкы кыяфәтенә карата таләпләр;

2 дәрес: «Намаз дәресләре»: намазның фазыйләтләре, дога кылу һәм намаз уку тәртибе;

3 дәрес: «Гакыйдә дәресе»: гакыйдә, ислам гакыйдәсенең әһәмияте;

4 дәрес: «Сира дәресе»: Мөхәммәд пәйгамбәребез, аның тормышы һәм эшчәнлеге;

5 дәрес: «Ураза дәресләре»: ураза тоту тәртипләре, уразаның әһәмияте һәм кагыйдәләре, зәкәт, хаҗ кылу, хәрам һәм хәләл.

«Бер көндә белем алу мәктәбе»ндә дәресләр түләүсез һәм атнага бер тапкыр якшәмбе көннәрендә Казанның Галиев мәчетендә узды. Ислам нигезләрен өйрәнергә килүчеләрне дини гыйлемнәре булган яшь волонтерлар укытты, мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин гакыйдә буенча лекция, Зәкәрия хәзрәт Тимганов кереш лекция үткәрде. Дәресләр ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым оештырылды.

Уку дәверендә шәкертләргә яулык-түбәтәйләр, дини китаплар, тәсбих кебек бүләкләр, ә ябылу тантанасында сертификатлар белән Коръән китаплары тапшырылды.

Ябылу тантанасында Камил хәзрәт Сәмигуллинның катнашуы, үгет-нәсыйхәтләрен җиткерүе укучылар өчен көтелгән вакыйга булды. Очрашу барышында Татарстан мөфтие мөфтиятнең эшчәнлеге турында мәгълүмат бирде, Рамазан аенда игелекле гамәлләр кылырга чакырды, шәкертләрнең сорауларына җавап бирде.

Әйтергә кирәк, шушы кыска гына вакыт аралыгында, дин белән күптән кызыксынган, әмма сорауларына җаваплар таба алмаган, нәрсәдәндер куркып калган кешеләр намазга басты, хатын-кызлар арасында көндәлек тормышта яулык бәйләп йөри башлаучылар булды, күбесенең Коръән укуырга өйрәнергә теләкләре туды. Димәк, оештыручылар үз максатларына ирештеләр.

Проектта катнашучылар өчен бу беренче адым гына, киләчәктә алар укуларын мәчетләр каршындагы курсларда, аннан соң мәдрәсәләрдә дәвам итәчәкләр, дигән өметтә калабыз.





# Коръәндә дәва: шәригать һәм медицина



## «Аллаһтан ныклы иман һәм сәламәтлек сорагыз ...»

Аллаһы Тәгалә һәрбер мөселманга шәригать кушканча яшәргә боерды. Кеше Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәү өчен шәригать хөкемнәрен белергә, хәләл белән хәрамны аера алырга тиеш. Белми икән, ул аны үти алмый. Шуңа күрә дә Исламда белем алуга зур игътибар бирелә.

Сәламәтлек – Аллаһы Тәгаләдән кешегә бирелгән иң зур нигъмәтләрнең берсе. Без еш кына: «Сәламәтлек булса, бар да була», – дибез. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм дә: «Иртән сау-сәламәт, имин һәм ризыгы булган хәлдә уянган кеше бөтен дөньяга ия», – дигән.

Сәламәтлек безне бу дөньяда бәхетле итсә, ныклы иман безне ахирәттә бәхетле булуга әзерли. Шуңа күрә Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Аллаһтан ныклы иман һәм сәламәтлек сорагыз. Чөнки иман соңында сәламәтлектән өстен нәрсә юктыр», – дип әйткән

Бу дөнья тормышында адәм баласын төрле хәлләр көтә, һәм ул үзенең никадәр зәгыйфь һәм Аллаһка никадәр мохтаҗ икәнлегенә кат-кат инана. Мондый хәлләргә психик һәм физик төрдәге төрле авырулар, чирләр дә керә.

Әлбәттә, һәрбер авыруның килеп чыгуының матди һәм рухи сәбәпләре бар. Иң беренче чиратта алар Аллаһның Үзенә генә билгеле булган хикмәтләр белән, тәкъ-диребезгә язылган буенча килеп чыгалар. Алар кешенең иманын, игътикадын, яки башына килгән бәла-казаларга сабырлыгын, чыдамлыгын сынау өчен бирелергә мөмкин. Шулай ук, алар аны гөнаһлардан пакьләү өчен дә хезмәт итәргә мөмкиннәр. Аллаһ Үзенең колын шул дәрәҗәдә сынарга мөмкин ки, Раббысы каршына килгәндә аның бернинди дә гөнаһы калмаган булыр. Шулай ук, башына төшкән борчу, мәшәкать, чирләр Аллаһының тәкъдиренә риза булган, сабыр иткән өчен кешегә Раббысы хозурында дәрәҗәсен күтәрү өчен дә бирелергә мөмкиннәр.

Авыруларга дәва эзләү һәм дәвалану риза, канәгать һәм сабыр булуга каршы килми. Чөнки Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) үзе дә дәваланган һәм сәхабәләренә дә: «Дәваланыгыз!» – дип дәваланырга кушкан. Шул җәһәттән күп кенә киңәшләр дә биргән. Шуның белән бергә, мөселман дәваның бер сәбәп кенә, ә шифаның Аллаһ кулында икәнлеген белә.

Ибраһим галәйһиссәләм бервакыт Аллаһы Тәгаләдән: «Әй Раббым! Авырулар кайдан килә?» – дип сораган. Аллаһы Тәгалә: «Миннән», – дип җавап биргән. Ибраһим галәйһиссәләм: «Шифа кайдан килә?» – дип сораган. Аллаһы Тәгалә: «Миннән», – дип җавап биргән. Ибраһим галәйһиссәләм: «Шулай булгач, табиб кем була соң?» – дип сораган. Аллаһы Тәгалә: «Мин аның кулына дәвалау чараларын биреп куйган кеше», – дип җавап биргән.

## Иң яхшы дәва – Коръәни Кәримдер

Иң яхшы һәм нәтиҗәле дәваларның берсе – Аллаһның шифалы сүзләре – Коръәни Кәримдер. Шәригатьтә Коръәннең төрле психик һәм физик авыруларга карата иң нәтиҗәле дәва булуы расланган. Ләкин моңа нык ышану һәм нәтиҗә ясауда ашыкмау таләп ителә. Бу нәрсә Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) заманыннан алып хәзерге көнгәчә тәҗрибә кылып килинә. Бик күпләр чирләренә сихәт, шифа табудан өмет өзгәннән соң Коръәни Кәрим белән төзәләләр.

Аллаһка мактаулар булсын, Ул Үзенең китабы Коръәндә болай дип әйтә:

**«Без Коръәндә мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәт булган аятьләр иңдерәбез».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:82

Интернет чыганакларда хәбәр ителгәнчә, күптән түгел Нидерланд психологы профессор Ван дер Ховен Коръәни Кәримне уку һәм «Аллаһ» сүзен кабатлау вакытында тап булган ачышы турында хәбәр итә.

Профессор үзенең ачышын өч ел буена күп кенә кешеләр өстендә алып барган тирән эзләнүләр тәҗрибәсе белән раслый. Аның пациентлары мөселман булмый, күпләре исә гарәпчә бер сүз дә белмиләр. Аларга «Аллаһ» сүзен дөрес итеп әйтергә өйрәтәләр. Нәтиҗә искиткеч була, бигрәк тә төшенкелеккә бирелү һәм психик киеренкелек белән җәфа чигүчеләр уңай нәтиҗә алалар.

Психолог Ван дер Ховен болай ди: «Коръәнне гарәпчә даими укучылар һәртөрле психик авырулардан имин булалар. Чөнки анда «Аллаһ» сүзе күп мәртәбә кабатлана».

Шуның белән бергә, профессор «Аллаһ» сүзендәге һәрбер хәрефнең психик авыруларны дәвалаганда уйнаган ролен аңлата. Мәсәлән, «хәмзә» белән «әлиф» сулышны контрольдә тотып, сулыш юлының эшчәнлеген яхшырта. «Ләм» – сулышны җиңеләйтә. Ахыргы хәреф «һә» үпкә белән йөрәкне тоташтыра. Бу тоташу, үз чиратында, йөрәк тибешен тәртипкә сала.

Бу ачыштагы иң кызыклы факт шул – Ван дер Ховен мөселман түгел.

Аллаһка мактаулар булсын, Ул Үзенең серләрен кемгә теләсә, шуңа ача:

**«Аллаһы Тәгалә хикмәтне теләгән кешесенә бирә. Тәхкыйк, кемгә хикмәт бирелсә, ул кешегә Аллаһы Тәгаләдән күп хәерләр бирелде».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:269

Хәзерге чорда медицина фәнендә күп ачышлар ясыйлар, аларның барысын да Коръән Кәримдә 14 мең ел элек Аллаһы Тәгалә тасвирлаган.

Коръәндә, бу китап – Аллаһтан, һәм кешелек аны хак юлны күрсәтә торган кулланма итеп кабул итәргә тиеш, диелә. Коръән – кешенең әхлагын югары күтәрә торган китап, ул күңел авыруларын дәвалый, Гарәбстан ярымутравында бер исерекне дә калдырмый, кечкенә кызларны тере килеш күмеп кую йоласын юкка чыгара. Коръән – нинди олуг сүз!

Коръән – бөек китап, ул Кыямәт көненә кадәр сакланачак, беркайчан да үзгәртелмәгән бердәнбер китап ул. Коръән уку җанны сафлардыруга, тәкъвалыкны арттыруга ярдәм итә. Коръән укучы шуны аңлый: дин гыйбадәт кенә түгел, ә гамәлләр дә; дини йолалар белән тормыш эшләрен үтәү. Мөселман үзе генә яшәми, ә җәмгыятьне дә матурларга тели.

■ **Алсу Җәббарова, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте**

# Хәтфә гөл белән тирәк кыйссасы

Хәтфә гөл белән тирәк вакыйгасы безгә үз-үзеңә ышанганлыкның, масаюның нинди аянычлы нәтиҗәләргә китерүен күрсәтә.

Бервакыт ботаклары күккә күтәрелгән зур гына тирәк янында кечкенә генә хәтфә гөл шытып чыга. Яз җитү белән ул тиз арада бик биек үсеп китә һәм тирәкне уратып ала. Мул яуган яңгырлар һәм кояш та кыздырганлыктан хәтфә гөл тирәкнең очына кадәр үсә.

Көннәрнең берендә хәтфә гөл тирәктән сорый: «Бу кадәр биеклеккә син ничә ай дәвамында ирештең?» Тирәк аңа: «Ун ел дәвамында», – дип җавап бирә. Хәтфә гөл көлеп җибәрә һәм үз яфракларын горур гына тирбәтеп: «Ун ел дәвамында? Мин менә синең кебек биеклеккә ике ай эчендә ирештем», – дип әйтә. Тирәк: «Син дөрес әйтәсең», – дип әйтеп куя да, башка бер сүз дә эндәшми. Көн артыннан көннәр үтә. Җылы, матур җәйне салкын көз алыштыра. Беренче көзге салкын җилләрдән хәтфә гөлнең яфраклары туңа. Ул акрынлап бөрешеп, түбәнгә таба төшә башлый. Хәтфә гөл борчылып, тирәктән сорый: «Нәрсә бу минем белән?» Тирәк аңа: «Син үләсең», – ди. «Ни өчен?» – дип сорый хәтфә гөл. Тирәк аңа түбәндәгечә җавап кайтара: «Чөнки ике ай эчендә син, мин ун ел дәвамында ирешкән биеклеккә җитәргә теләдең».

# Вакыт бар әле

Бер кешенең өй алдында чүп үләннәре үскән. Алар шундый зур булып үскәннәр ки, узып китүчеләргә комачаулый башлаганнар. Бу хәлне күреп, берәү хуҗаны кисәткән: «Соң булганчы өзеп ташла инде аларны». Ләкин аның кисәтүеннән бернәрсә дә үзгәрмәгән. Теге кеше: «Бүген булмаса, иртәгә булыр», дип һаман кичектерә килгән. Чүп үләннәре көннән-көн үскәннәр, узып китүчеләргә генә түгел, хәтта хуҗаның үзенә дә комачаулый башлаганнар.

Моны күреп, берәү янә аңа әйткән: «Син һаман бу эшеңне иртәгәге көнгә кичектерәсең. Син шуны бел, бу чүп үләннәре үсәләр һәм көннән-көн ныгыйлар, яшәрәләр. Ә син исә вакыт үткән саен көчсезләнәсең, картаясың».

Көчсезлек һәм ялгышлар да кешегә хас нәрсәләр. Әгәр дә аларны төзәтмәсәң, вакыт үтү белән алар чүп үләннәре кебек тамыр җибәрәчәк һәм башкаларга гына түгел, ә иң беренче чиратта кешенең үзенә зыян китерәчәкләр. Шуңа да кешегә үзенең көчсезлеге белән көрәшергә иң кулай вакыт булып яшь вакыты санала.

Моның турында безгә Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһының сәламе һәм рәхмәте булсын) хәдисе дә искә төшерә: «Кешеләр ике нигъмәтнең кадерен белмиләр: сәламәтлек һәм буш вакытның» (Бохари, Рикак, 1).

# Юлдагы таш

Бервакыт бер патша сарайга илтә торган юлга бик зур таш куя. Үзе исә тәрәзә янына утырып, күзәтә. Иртәдән көндезгә чаклы бу юл аша бик күп танылган кешеләр, бай сәүдәгәрләр, сарай әһелләре һәм гади кешеләр уза. Барысы да бу ташны әйләнеп узалар һәм үз юлларын дәвам итәләр; күбесе зарлана, халыктан зур салымнар алып та, юлларны чисталыкта тота алмый дип патшаны тәнкыйтьлиләр.


Ниһаять, сарайга җиләк-җимеш һәм яшелчәләр белән сәүдә итүче крестьян килә. Юлдагы ташны күреп, ул аркасындагы авыр йөкне төшерә һәм ташны этә башлый. Бик зур тырышлык күрсәтеп, тиргә һәм канга батып булса да ул юлдан ташны күчерә. Инде аркасына янәдән авыр йөген салырга җыенганда, таш яткан урында капчык таба. Шул капчыкны алып, ача. Алтын белән тулы капчыкта бер язу таба. Анда болай язылган: «Бу алтын – юлдан ташны алучыга». Бу язуны патша язган була.

Бу вакыйганы сөйләгәндә, кешеләр үзләреннән «крестьян безнең әле күпләребезгә таныш булмаган сабак алган», дип өстиләр: «Һәрбер киртә – тормышны яхшыртуга бер мөмкинлек ул».

# Агач

Бервакыт хөкемдар үз яраннары белән юлга чыга. Юлда ул агач утыртырга тырышкан карт кешене очрата һәм аннан сорый: «Нигә син агач утыртып газапланасың? Син бит барыбер бу агач җимешләренең тәмен татый алмаячаксың». Теге карт моңа җавап итеп әйтә: «Әй улым, бу агачның җимешләрен татып карау мөһим түгел. Менә без үзебезнең бабаларыбыз утырткан агачларның җимешләрен ашаган кебек, безнең дә оныкларыбыз без утырткан агачларның җимешләреннән авыз итәрләр». Бу җавап падишаһка бик ошый һәм ул бу картка янчык белән алтын бирә. Карт, елмаеп, әйтә: «Менә күрәсеңме, улым, мин утырткан агачлар җимеш бирә башладылар инде». Падишаһ картның бу җавабын да бүләксез калдырмый һәм аңа тагын янчык белән алтын бирә. Зирәк карт шулчак: «Барлык агачлар да елга бер генә тапкыр җимеш бирәләр, ә минем агачым инде ике тапкыр җимеш бирде», – дип әйтә. Бу җавап белән дә бик канәгать булган падишаһ бу картка янә янчык белән алтын бирергә боера, ләкин вәзире аны туктата. Ул: «Әй минем падишаһым, тиз арада моннан китик, алайса бу карт агач урынына бөтен казнаны утыртып куяр», – ди.

# Караңгылыктагы фил



Бервакыт индуслар беркайчан да фил күрмәгән кешеләргә фил күрсәтергә булганнар. Филне күрергә теләүчеләр барысы да бергәләп караңгы сарайга җыелалар, ләкин аны күрә алмыйлар, чөнки бик нык караңгы була.

Үзләренең кызыксынучанлыкларын басар өчен боларның һәрберсе филгә кагылып карый, шулай итеп аның нәрсәгә охшаганын белергә телиләр. Араларыннан берсе филнең колагына кагылып: «Фил тагаракка охшаган», – дип әйтә. Икенчесе аның тәпиләренә кагылып: «Фил баганага охшаган», – ди. Өченчесе аның аркасына кагылып үтә һәм әйтә: «Фил тәхеткә охшаш». Шул рәвешле, аларның һәрберсе филнең төрле җирләренә орынып, үзләре аңлаганча сөйлиләр. Кешеләр үзара килешмәгәннәр, шуңа да алар арасында фикер каршылыклары килеп чыккан. Аларда хакыйкатьне күрергә ярдәм иткән яктылык булмаган. Мәвләнә әйткәнчә, «Хис-тойгылар уч төбенә охшаш, ә уч төбе генә филне колачлый алмый». Аларның һәрберсе хакыйкатьне үз күзаллаулары аша күреп, үзенчә аңлаган.

Әмма, чын хакыйкать кешеләр күргәннәрдән тора. Әгәр аларда яктылык һәм гыйлем булса, алар хакыйкатьне күрерләр, аңларлар иде һәм үзара да каршылыклар тумас иде.

■ **Сәхифәне Лилия Хәләфетдинова әзерләде**




# «Мөхәммәд» китабы нәшер ителде

Изге Рамазан аенда ТР Мөселманнары Диния Нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты татар һәм рус телләрендә мәшһүр дин әһеле Ризаэтдин бине Фәхретдиннең (1859-1936) «Мөхәммәд» исемле китабын дөньяга чыгарды. Басмада автор сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) тормышы һәм эшчәнлеге, исламның таралышы турында кыскача мәгълүмат бирә. Китапта шулай ук Пәйгамбәребезнең гаиләсе, балалары, хатыннары турында да сүз бара.

Басма киң катлам укучыларны, ислам һәм татар мәгърифәтчеләренең дини мирасы белән кызыксынучыларны җәлеп итәчәк. Хезмәт рус һәм татар телләрендә нәшер ителде.

**Әлеге китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин.**

**Телефон:** +7 (843) 258-52-01




## КАЗАН ӨЧЕН ИЮНЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.06.2018 | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 12:00 | 17:24 | 20:16 | 21:46 |
| 02.06.2018 | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 12:00 | 17:24 | 20:17 | 21:47 |
| 03.06.2018 | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 12:00 | 17:25 | 20:18 | 21:48 |
| 04.06.2018 | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 12:00 | 17:26 | 20:20 | 21:50 |
| 05.06.2018 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:26 | 20:21 | 21:51 |
| 06.06.2018 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:27 | 20:22 | 21:52 |
| 07.06.2018 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:23 | 21:53 |
| 08.06.2018 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 09.06.2018 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 10.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:29 | 20:26 | 21:56 |
| 11.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 12.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:28 | 21:58 |
| 13.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:28 | 21:58 |
| 14.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| Ураза гаете мөбарәк булсын! | | | | | | | |
| 15.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 16.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 17.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:31 | 22:01 |
| 18.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 19.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 20.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 21.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 22.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 23.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 24.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 25.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 26.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 27.06.2018 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 28.06.2018 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 29.06.2018 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 30.06.2018 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 31.05.2018 | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 12:00 | 17:23 | 20:15 | 21:45 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Май саны, №5 (274)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДһӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2749
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Казан шәһәренең мәчетләрендә 30 нче майда таратыла.
График буенча бу санга 28 нче май көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.